Дәүләтләрнең мөнәсәбәтләрендә сәясәтнең санкция инструментлары көчәю шартларында федератив дәүләтләр субъектлары өчен яңа мөмкинлекләр ачыла. Аерым алганда, Татарстан килеп чыга торган мәсьәләләрне барлык юнәлешләрдә хезмәттәшлекне киңәйтү юлы белән, иң элек икътисадта, шулай ук кеше капиталы сыйфатын арттыру өлешендә дә, үсешләрендә алга киткән илләрдәге төрле структуралар белән хәл итәргә омтыла, чөнки Стратегиядә әйтелгән дөньякүләм дәрәҗәдәге конкурентлык сәләтенә ирешү үсешләрендә алга киткән икътисадлар белән элемтәләрне саклауны һәм киңәйтүне таләп итә. Төбәкара хезмәттәшлек һәм аерым компанияләр, үсешләрендә алга киткән илләрнең университетлары белән элемтәләрне ныгыту санкцияләр инструментларын билгеле бер дәрәҗәдә йомшарту мөмкинлеге булдыра. Шуларга туры китереп, Стратегияне гамәлгә ашыру контексты билгеле бер төзәтмәләр кертүне, шулай ук глобаль трендларны өйрәнүне, даими анализлауны һәм тиешле чаралар күрүне таләп итә.»;

б) 1.2 бүлекчәнең 1.2.2 пунктының 1.3 нче таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«1.3 нче таблица. Татарстан Республикасының рейтингларда урыннары**

| Рейтинг | Татарстан Республикасының урыны/ урыннарның гомуми саны | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | **2012** | **2013** | **2014** | **2015** | **2016** | **2017** |
| RCI – регионнар конкуренциясе индексы | 3 | 3 | 4 | 4 | 4 | 4 |
| Эксперт РА – инвестицияләр җәлеп итү рейтингы | 1А | 1А | 2А | 2А | 2А | 2А |
| Регионнарның инвестицияләр җәлеп итүнең илкүләм рейтингы | - | - | I төркем | 1 урын | 1 урын | 1 урын |
| Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнарының эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү («Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнарының эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү турында» Россия Федерациясе Президентының 2017 елның 14 ноябрендәге 548 номерлы Указы) | 1 | 1 | 1 | 3 | 1 | |

»;

2) 2 бүлектә:

а) 2.1 бүлекчәдә:

утыз тугызынчы абзацта «үстерү» сүзеннән соң «һәм бүленгән транспорт-логистика комплексын булдыру» сүзләрен өстәргә;

кырык икенче абзацта «төрләре» сүзеннән соң «һәм социаль, иҗтимагый һәм транспорт инфраструктурасын үстерү» сүзләрен өстәргә;

«Россия Федерациясенең социаль-икътисадый үсеше приоритетлары һәм максатлары белән килештерү» кисәген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«Россия Федерациясенең социаль-икътисадый үсеше приоритетлары һәм максатлары белән килештерү**

Татарстан Республикасы үсеше приоритетлары һәм максатлары Россия Федерациясе үсеше приоритетлары һәм максатлары белән килештерелгән, алар түбәндәге документларда тәгъбир ителгән: Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә юлламасы, 2020 ел чорына кадәр Россия Федерациясенең озак сроклы социаль-икътисадый үсеш концепциясе, 2024 ел чорына кадәр Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары һәм стратегик бурычлары, 2025 ел чорына кадәр Россия Федерациясенең региональ үсешенең дәүләт сәясәте нигезләре, Россия Федерациясенең милли иминлек стратегиясе, Россия Федерациясенең азык-төлек иминлеге доктринасы, 2025 ел чорына кадәр Россия Федерациясенең дәүләт милли сәясәте стратегиясе, Россия Федерациясенең фәнни-технологик үсеш стратегиясе, 2017 – 2030 елларга Россия Федерациясендә мәгълүмати җәмгыять үстерү стратегиясе, 2030 ел чорына кадәр Россия Федерациясенең икътисадый иминлек стратегиясе, 2030 ел чорына кадәр дәүләт мәдәни сәясәте стратегиясе, 2025 ел чорына кадәр Россия Федерациясенең пространство үсеше стратегиясе, «ИнноКам» территориаль аерымланган инновацияле-җитештерү үзәген булдыру концепциясе, шулай ук федераль дәрәҗәдә кабул ителгән һәм расланган башка озак сроклы тармак стратегияләре, концепцияләре һәм доктриналары.

Россиянең стратегик приоритетларын берничә төркемгә тупларга була, алар Стратегиянең өч өстенлекле темасында чагылыш таба (2.1 нче таблица).

Татарстан Республикасы федераль приоритетларны гамәлгә ашыруда иң зур өлешне түбәндәге юнәлешләр буенча кертәчәк:

- инновацияле икътисад;
- азык-төлек иминлеге;
- транспорт-транзит системасы, халыкара транспорт коридорлары;
- кешенең байлык стандартларының, социаль иминлекнең һәм татулыкның югары булуын тәэмин итү;
- демография;
- сәламәтлек саклау;
- мәгариф;
- торак һәм шәһәр мохите;
- экология;
- имин һәм сыйфатлы автомобиль юллары;
- хезмәт җитештерүчәнлеге һәм эш белән тәэмин итүгә ярдәм;
- фән;

- цифрлы икътисад;
- мәдәният;
- кече һәм урта эшкуарлык, индивидуаль эшкуарлык инициативасына ярдәм;
- халыкара кооперация һәм экспорт.

**2.1 нче таблица. Татарстан стратегиясендә Россиянең стратегик приоритетлары чагылышы**

| Россиянең стратегик приоритетлары | Татарстан стратегиясенең өстенлекле темалары |
|---|---|
| • Кешенең байлык стандартларының, социаль иминлекнең һәм татулыкның югары булуын тәэмин итү<br>• Гражданнарның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау, халыкның закон кушканча эшләү дәрәҗәсен арттыру, суд системасы эшен яхшырту, территориаль җәмәгать үзидарәсен активлаштыру<br>• Россия Федерациясе халкы санының тотрыклы табигый артуын тәэмин итү<br>• Көтелгән гомер озынлыгын 78 яшькә җиткерү (2030 елга – 80 яшькә)<br>• Россия Федерациясендә ярлылык дәрәҗәсен ике мәртәбә киметү<br>• Гражданнарның реаль керемнәренең тотрыклы үсешен, шулай ук пенсия белән тәэмин итү дәрәҗәсен инфляция дәрәҗәсеннән арттыруны тәэмин итү | **Кеше капиталы** |
| • Баланслы пространство-территориаль үсеш<br>• Махсус икътисадый зоналар һәм алда барып үстерү зоналары үсеше, территориаль икътисадый кластерларга ярдәм күрсәтү, агломерация процессларына идарә итү системаларын булдыру<br>• Россиянең хуҗалык үзара элемтәләрен үстерүгә ярдәм итә торган транспорт-транзит системасын үстерү<br>• Ел саен кимендә 5 миллион гаиләнең торак шартларын яхшырту | **Пространство** |
| • Белемнәргә нигезләнгән яңа нәтиҗәле икътисад булдыру, инновация эшчәнлеген, икътисадның югары технологияле секторларын, массакүләм инновацияләрне төп таратучы буларак кече эшкуарлыкны үстерү<br>• Россиянең дөньякүләм базарларда конкурентлык сәләтен арттыру, Россия икътисадының традицион тармакларын үстерү<br>• Норматив хокукый базаны камилләштерү, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының эшчәнлек нәтиҗәлелеген арттыру, граждан | **Икътисад һәм идарә итү** |

| | |
|---|---|
| җәмгыяте институтларының әһәмиятен көчәйтү | |
| • Дәүләт, гражданнар һәм җәмгыять иминлеге<br>• Икътисадта һәм социаль өлкәдә цифрлы технологияләрне тизләтелгән рәвештә гамәлгә кертүне тәэмин итү<br>• Россия Федерациясенең технологик үсешен тизләтү, технологик инновацияләрне гамәлгә ашыручы оешмалар санын аларның гомуми саныннан 50 процентка җиткерү<br>• Россия Федерациясенең дөньяның иң эре биш икътисады арасына керүе, макроикътисадый тотрыклылык саклanган хәлдә икътисадый үсеш темпларын дөньякүләм темплардан арттыруны, шул исәптән инфляция дәрәҗәсен 4 проценттан да артмаган дәрәҗәдә тәэмин итү<br>• Икътисадның төп тармакларында, иң элек эшкәртү сәнәгатендә һәм агросәнәгать комплексында, заманча технологияләр нигезендә үсә торган һәм югары квалификацияле кадрлар белән тәэмин ителгән экспортка ориентлашкан югары җитештерүчәнлеккә ия сектор булдыру | |

»;

б) 2.3 бүлекчәдә:

2.2 нче таблицада:

«Көтелгән гомер озынлыгы, елларда» позициясен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Көтелгән гомер озынлыгы, елларда | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 72,12 | 72,3 | 72,4 | 72,4 | 72,5 |
| Төп сценарий буенча | 72,12 | 74,3 | 74,6 | 78,0 | 80,0 |
| Оптимистик сценарий буенча | 72,12 | 74,4 | 76,71 | 79,07 | 80,0»; |

«Эшсезлек дәрәҗәсе (МОТ методологиясе буенча), %» позициясен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Эшсезлек дәрәҗәсе (МОТ методологиясе буенча), % | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 4,0 | 3,6 | 3,6 | 3,5 | 3,5 |
| Төп сценарий буенча | 4,0 | 3,6 | 3,5 | 3,5 | 3,5 |
| Оптимистик сценарий буенча | 4,0 | 3,6 | 3,5 | 3,5 | 3,4»; |

«Югары уку йортларын тәмамлаучыларның укуны тәмамлаганнан соң беренче елда эшкә урнашкан өлеше, %» позициясен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Югары белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларның укуны тәмамлаганнан соң беренче елда эшкә урнашкан өлеше, % | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 54,8 | 55,7 | 57,7 | 58,7 | 60,0 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Төп сценарий буенча | 54,8 | 56,7 | 65,0 | 65,0 | 65,0 |
| Оптимистик сценарий буенча | 54,8 | 70,0 | 73,5 | 76,0 | 80,0»; |

«Татарстан Республикасында югары белем бирү мәгариф оешмаларындагы студентларның гомуми саныннан чит ил студентлары өлеше, %» позициясен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Татарстан Республикасында югары белем бирү мәгариф оешмаларындагы студентларның гомуми саныннан чит ил студентлары өлеше, % | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 2,6 | 5,4 | 6,5 | 7,0 | 7,5 |
| Төп сценарий буенча | 2,6 | 5,8 | 6,8 | 7,3 | 7,8 |
| Оптимистик сценарий буенча | 2,6 | 6,0 | 7,0 | 7,5 | 8,0»; |

«Халыкның физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче өлеше, %» позициясен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Халыкның физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче өлеше, % | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 31,0 | 45,0 | 50,0 | 55,0 | 60,0 |
| Төп сценарий буенча | 31,0 | 45,0 | 50,0 | 57,0 | 63,0 |
| Оптимистик сценарий буенча | 31,0 | 45,0 | 50,0 | 58,0 | 65,0»; |

«Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме чараларын алучылар өлеше, %» позициясен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме чараларын алучылар өлеше, % | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 2,3 | 70,0 | 80,0 | 83,0 | 85,0 |
| Төп сценарий буенча | 2,3 | 70,0 | 85,0 | 88,0 | 90,0 |
| Оптимистик сценарий буенча | 2,3 | 75,0 | 88,0 | 90,0 | 93,0»; |

«Тизйөрешле һәм бик тизйөрешле тимер юл линияләре озынлыгы, км» позициясен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Тизйөрешле һәм бик тизйөрешле тимер юл линияләре озынлыгы, км | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 0 | 0 | 0 | 0 | 43 |
| Төп сценарий буенча | 0 | 0 | 0 | 0 | 336 |
| Оптимистик сценарий буенча | 0 | 0 | 0 | 43 | 336»; |

«Аэропортларның пассажирлар әйләнеше, бер елга млн. кешедә» позициясен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Аэропортларның пассажирлар ташкыны, бер елга млн. кешедә | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 2,25 | 2,4 | 2,6 | 2,8 | 3,0 |
| Төп сценарий буенча | 2,25 | 3,7 | 4,3 | 5,5 | 7,3 |
| Оптимистик сценарий буенча | 2,25 | 4,5 | 5,4 | 7,3 | 10,0»; |

«Пычранган җирләрнең гомуми мәйданыннан яңадан торгызылган җирләрнең өлеше, %» позициясен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Пычранган җирләрнең гомуми мәйданыннан яңадан торгызылган җирләрнең өлеше, % | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 37,0 | 40,0 | 41,0 | 42,0 | 44,0 |
| Төп сценарий буенча | 37,0 | 44,0 | 45,0 | 46,0 | 50,0 |
| Оптимистик сценарий буенча | 37,0 | 50,0 | 60,0 | 70,0 | 80,0»; |

«Чит илләрнең турыдан-туры барлык тупланган инвестицияләре, АКШ долларларында (млн.)» позициясен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Чит илләрнең турыдан-туры барлык тупланган инвестицияләре, АКШ долларларында (млн.) | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | | 1745,85 | 2494,53 | 3350,14 | 5442,88 |
| Төп сценарий буенча | | 1747,64 | 2516,45 | 3417,2 | 5707,91 |
| Оптимистик сценарий буенча | | 1748,90 | 2530,85 | 3461,47 | 5885,09»; |

2.3 нче таблицадан соң:

унөченче абзацта «(технологик)» сүзе татарча текстта үзгәрешсез кала;

ундүртенче абзацта «йөртү» сүзеннән соң «һәм йөк ташу» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлектәге яңа унҗиденче абзац өстәргә:

«халыкның экологик иминлеге тәэмин ителә;»;

унҗиденче – егерме икенче абзацларны тиешенчә унсигезенче – егерме өченче абзацлар дип санарга;

3) 3 бүлектә:

а) 3.1 бүлекчәдә:

1 нче искәрмәдә «3.3 бүлектә» сүзләрен «3.3 бүлекчәдә» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 рәсемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« Кеше капиталын туплау стратегиясе

Кеше капиталын булдыруның төп факторлары

Кеше капиталын туплауның төп шартлары

Халык саны динамикасы

Мәгариф – Татарстанның үсеш нигезе

Сәламәтлекне саклау һәм озаграк яшәү

Һәркем файдалана алырлык мәдәният

Халыкны эш белән тәэмин итү, хезмәт җитештерүчәнлеге. Социаль яклау

**Максатлар системасы (максатчан күзаллау 2030)**

1. Тупланган кеше капиталы Татарстан Республикасының конкурентлык сәләтен тәэмин итә

1.1. Татарстан – туучылар саны югары һәм халыкның миграция килүе тотрыклы булган үсүче регион

1.2. Мәгариф системасы җәмгыять һәм икътисад ихтыяҗларына туры килә торган кеше капиталын булдыруны тәэмин итә

1.3. Сәламәтлекне саклау һәм озак яшәү – халыкның һәм сәламәтлек саклау системасының приоритетлары

1.4. Мәдәни тормышның сыйфаты һәм төрлелеге кеше капиталын җәлеп итүнең һәм туплауның реаль факторларына әйләнде

1.5. Үзгәрүчән хезмәт базары, хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру, халыкны эш белән тәэмин итүгә булышу һәм социаль яклау системалары эш белән тәэмин итүнең нәтиҗәле булуын һәм кеше капиталына кертүдән конкурентлы керемнәр алуны тәэмин итә

**3.1 нче рәсем. Кеше капиталын туплау стратегиясенең структурасы һәм максатлар системасы**»;

3.1.1 пунктта:

«Максатчан күзаллау һәм бурычлар» бүлегендә:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3-1.1.0.1 Туучылар санының суммар коэффициентын арттыруны тәэмин итәргә.»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«3-1.1.0.8 Көтелгән сәламәт гомер озынлыгын 67 яшькә җиткерүне тәэмин итәргә.

3-1.1.0.9 Сәламәт яшәү рәвеше алып баручы гражданнар өлешен арттыруны тәэмин итәргә.»;

«Гамәлләр юнәлешләре» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гамәлләр юнәлешләре:

1) туучылар санының уңайлы динамикасын саклау (гаиләләргә максималь тулы дәрәҗәдә балаларга ихтыяҗны гамәлгә ашыру мөмкинлеген бирү шартларын тудыру):

- балалы гаиләләргә акчалата бирелә торган социаль ярдәм чараларының адреслылыгын арттыру;
- социаль ярдәм чараларын гаиләләрнең яшәү циклының төп стадияләре буенча нәтиҗәлерәк бүлү (хәзер күбесенчә бала 1,5 яшькә җиткәнче);
- балаларның үсеп җитүенә һәм аларны тәрбияләүгә ярдәм итә торган инфраструктура булдыру һәм үстерү;
- ата-аналарга балалар карауны икътисадый активлык белән бергә алып бару мөмкинлекләрен тәэмин итү;
- балалар туганда гаиләләргә финанс ярдәме;
- балалары булган хатын-кызларның хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру, өч яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем бирүнең 100 процентлы мөмкинлегенә ирешүне (2021 елга) дә кертеп;

2) үлүчеләр санын киметү һәм гомер озынлыгын арттыру:

- булдырмый калдыра ала торган үлемнәрне һәм иртә үлемнәрне киметү өлешендә сәламәтлек саклау системасын камилләштерү;
- үз-үзеңне саклау тәртибен үстерү һәм сәламәт, актив гомер озынлыгы өчен шартлар тудыру;
- өлкән буын гражданнарына системалы ярдәм итү һәм аларның тормыш сыйфатын яхшырту программаларын гамәлгә ашыру;
- халыкның барлык категорияләренә һәм төркемнәренә физик культура һәм спорт, массакүләм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру, шул исәптән спорт объектлары белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен арттыру, шулай ук спорт резервын әзерләү;
- гражданнарны сәламәт яшәү рәвеше алып баруга кызыксындыру системасын формалаштыру, сәламәт туклануны һәм зарарлы гадәтләрдән баш тартуны да кертеп;

3) халыкның миграция үсешен тәэмин итү (төрле категориядәге мигрантлар өчен регионның мигрантлар җәлеп итүчәнлеген арттыра торган икътисадый шартлар булдыру):

- сыйфатлы эш урыннары булдыру;

● инфраструктураны (торак, транспорт һ.б.ш.) үстерү, аренда торагы базарына ярдәм итү, шәһәр мохите сыйфатын яхшырту, кече бизнес өчен шартларны яхшырту;

● ике яклы хөкүмәтара килешүләр төзү һәм аларны гамәлгә ашыру;

● мигрантларның кабул итүче социумга интеграцияләнүен тәэмин итү (мигрантларның өстенлекле категорияләре өчен ярдәм итү режимын булдырырга);

● керемнәр дәрәҗәсен бердәйләштерү һәм социаль өлкә оешмалары хезмәт күрсәтүләреннән файдалана алу нигезендә шәһәрләрдә һәм авыл җирендә тормыш сыйфатындагы аерымлыкларны киметү;

● социаль, транспорт, икътисадый инфраструктура белән тәэмин ителешнең рациональ стандартын билгеләү;

● хезмәт базарында муниципальара һәм чик буе территорияләрендәге хезмәттәшлек өчен шартлар тудыру.

Татарстан Республикасында туучылар санын арттыруга юнәлдерелгән өстәмә чаралар буенча комплекслы план һәм «Татарстан Республикасында гаиләләрнең социаль-икътисадый хәлен яхшырту» программасы проекты.

Якындагы 10 – 15 елда тулаем Россия Федерациясендә халыкның яшь структурасындагы тискәре үзгәрешләрнең нәтиҗәсе буларак (актив репродуктив яшьтәге хатын-кызлар саны кимүе) Татарстан Республикасында туучылар саны кимиячәк. 2000 елларның икенче яртысыннан башланган, шул исәптән 2006 елда кабул ителгән актив демографик сәясәт чаралары белән стимуллаштырылган, туучылар саны күрсәткечләре артуның уңайлы тенденцияләренең дәвам итүе «1990 еллар кайтавазы»ның тискәре йогынтысын җиңеләйтергә мөмкин. Дөньякүләм тәҗрибә шуны күрсәтә, тууларга ярдәм итү чараларын алга таба үстермәгәндә һәм камилләштермәгәндә, аларның тәэсире бетә. Болай булмасын өчен, балалы гаиләләргә ярдәм итү чаралары аларның адреслылыгын арттыру, социаль ярдәм чараларын яшәү циклының төп стадияләре буенча нәтиҗәлерәк бүлү, шулай ук балалар тәрбияләүгә ярдәм итә торган инфраструктура булдыру һәм үстерү, ата-аналарга балалар карау бурычларын икътисадый активлык белән бергә алып бару мөмкинлекләрен тәэмин итү исәбенә оптимальләштерелергә тиеш.

Нәтиҗә: туучылар саны күрсәткечләренең алдагы үсеше (2030 елга туучылар санының тулаем коэффициенты күрсәткеченең 1,838 дәрәҗәсенә кадәр үсеше), балалы гаиләләр арасында ярлылыкның радикаль рәвештә кимүе, уңайлы график шартларында һәм тулы булмаган эш көне режимында, шулай ук ерактан торып эшләү шартларында хезмәт итү мөмкинлеге булган балалар тәрбияләүче хатын-кызлар өлеше артуы.

«Татарстан – Идел буена халыкны җәлеп итү үзәге» флагман проекты (3.1.6.1 пунктчасын кара)1

3.1.2 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле сигезенче һәм тугызынчы абзацлар өстәргә:

«6) мәгариф системасы Россия Федерациясе халыкларының рухи-әхлакый кыйммәтләре, тарихи һәм милли-мәдәни традицияләр нигезендә гармоник үсешле һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләүне тәэмин итәргә тиеш;

7) мәгариф системасы, Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм оешмалары ихтыяҗларыннан чыгып, анда формалаша торган күнекмәләрне, белем бирү траекторияләрен тәэмин итәргә тиеш.»;

сигезенче һәм тугызынчы абзацларны тиешенчә унынчы һәм унберенче абзацлар дип санарга;

3.1.2.1 пунктчадагы «Максатчан күзаллау һәм бурычлар» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Максатчан күзаллау һәм бурычлар

Ц-1.2.1 Гаиләләр балаларны һәрьяклап үстерүдә һәм аларны мәктәптә укуга әзерләүдә нәтиҗәле ярдәм белән тәэмин ителде.

З-1.2.1.1 Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белем бирү торышын, шулай ук мәктәпкәчә яшьтәге балаларның үсеш дәрәҗәсен һәрьяклап тикшерергә.

З-1.2.1.2 Уңайлы файдалану мөмкинлекләрен исәпкә алып, инфраструктураны яңартырга, заманча мультимедиа технологияләрен гамәлгә кертергә.

З-1.2.1.3 Мәктәпкәчә белем бирү өлкәсендә дәүләтнеке булмаган секторның өлешен арттырырга.

З-1.2.1.4 Гаиләләрдә һәм яслеләрдә балаларның үсешен кече яшьтән тәэмин итеп бару системасын булдырырга.

З-1.2.1.5 Балалар үсешен тәэмин итеп баруның ведомствоара координацияләү системасын эшләргә.

З-1.2.1.6 Авырлыкларны иртә ачыклау һәм аларны хәл итүдә булышу өчен балаларның үсешен индивидуаль тәэмин итеп бару системасын булдырырга.»;

3.1.2.2 пунктчада:

«Максатчан күзаллау һәм бурычлар» бүлегендә:

унөченче абзацта «граждан-патриотик,» сүзләреннән соң «ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык),» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«З-1.2.2.14 Педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри үсешенең илкүләм системасын кертү.»;

«Гамәлләр юнәлешләре» бүлегендә:

тугызынчы абзацка «сәләтле» сүзе алдыннан «гаделлек, гомумилек принципларына нигезләнгән һәм белем алучыларның үзбилгеләнешенә һәм һөнәри ориентлашуына юнәлдерелгән» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«11) төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү баскычларында укытуның һәм тәрбия бирүнең яңа алымнарын, белем алучыларның төп күнекмәләрне үзләштерүен тәэмин итә торган белем бирү технологияләрен гамәлгә кертү, аларның укуга кызыксынуын һәм белем бирү процессына җәлеп ителүен арттыру, шулай ук “Технология” предметы өлкәсенең эчтәлеген яңарту һәм аны укыту алымнарын камилләштерү;

12) белем бирү нәтиҗәләре түбән булган мәктәпләрдә һәм уңайсыз социаль шартларда эшләүче мәктәпләрдә региональ проектларны гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәләрен тарату юлы белән белем бирү сыйфатын яхшырту.»;

«Чаралар исемлеге» бүлегенең икенче абзацында «төзү» сүзеннән соң «, шулай ук белем бирү нәтиҗәләре түбән булган мәктәпләрдә һәм уңайсыз социаль шартларда эшләүче мәктәпләрдә белем бирү сыйфатын яхшырту һәм метапредмет күнекмәләрен һәм компетенцияләрен бәяләү һәм үстерү механизмнарын гамәлгә кертү» сүзләрен өстәргә;

3.1.2.3 пунктчасында:

«Максатчан күзаллау һәм бурычлар» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«3-1.2.3.7 Формаль булмаган белем бирүне үстерүгә һәм яшьләрнең үзлегеңнән укып белем алуга кызыксынуын арттыруга юнәлдерелгән инновацияле белем бирү технологияләрен гамәлгә кертергә.

3-1.2.3.8 Урта һөнәри белем бирү өлкәсендә тәрбия эше системасын формалаштырырга һәм үстерергә.»;

«Гамәлләр юнәлешләре» бүлегендә:

түбәндәге эчтәлекле яңа унөченче – унҗиденче абзацлар өстәргә:

«12) һөнәри белем бирүне модернизацияләү, шул исәптән адаптив, гамәли юнәлдерелгән һәм үзгәрүчән белем бирү программаларын гамәлгә кертү ярдәмендә;

13) кадрларны әзерләүнең һәм яңадан әзерләүнең кыска сроклы рәвешләрен тәэмин итү механизмын булдыру, шул исәптән эш бирүчеләрнең шәхси кабинетлары аша онлайн форматта;

14) дәүләт заказын һәм икътисад ихтыяҗларын исәпкә алып, урта һөнәри белем бирү оешмаларына укуга кабул итүнең контроль саннарын формалаштыру;

15) мәгариф оешмаларында яшьләр үзидарәсе институтларын үстерү;

16) Татарстан Республикасы икътисадында таләп ителгән әзерлек юнәлешләре буенча максатчан укытуны гамәлгә ашыру кысаларында предприятиеләр – кадрлар заказчыларының һәм һөнәри белем бирү оешмаларының уртак хезмәттәшлеген үстерү.»;

унөченче абзацны унсигезенче абзац дип санарга;

3.1.2.4 пунктчасында:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.2.4. Фән һәм югары белем бирү»;

«Максатчан күзаллау һәм бурычлар» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«3-1.2.4.9 Россиянең һәм чит илләрнең әйдәп баручы галимнәренә һәм яшь перспективалы тикшеренүчеләренә Татарстан Республикасында эшләүнең кызыклы булуын тәэмин итәргә.

3-1.2.4.10 Формаль булмаган белем бирүне үстерүгә һәм яшьләрнең үзлегеңнән укып белем алуга кызыксынуын арттыруга юнәлдерелгән инновацияле белем бирү технологияләрен гамәлгә кертергә.

3-1.2.4.11 Югары уку йортларында тәрбия эше системасын камилләштерергә.»;

«Гамәлләр юнәлешләре» бүлегендә:

җиденче абзацта «Россия Федерациясенең мәгариф һәм фән министрлыгы» сүзләрен «Россия Федерациясенең Фән һәм югары белем бирү министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлектәге яңа сигезенче – унберенче абзацлар өстәргә:

«• фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләрнең алдынгы инфраструктурасын булдыру;

• яшь галимнәргә фәнни тикшеренүләрне һәм эшләнмәләрне гамәлгә ашыру өчен шартлар тәэмин итә торган фәнни һәм фәнни-педагогик кадрларны әзерләүнең һәм аларны һөнәри үстерүнең тулы системасын булдыру;

• мәгариф оешмаларында яшьләр үзидарәсен үстерү;

• Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең сыйфат һәм сан ягыннан ихтыяҗлары нигезендә укуга кабул итүнең контроль саннары структурасын формалаштыру.»;

сигезенче абзацны уникенче абзац дип санарга;

3.1.3 пунктта:

«Максатчан күзаллау һәм бурычлар» бүлегендә:

өченче абзацта «үлүчеләр санын киметергә» сүзләрен төшереп калдырырга, «туберкулездан һ.б.)» сүзләреннән соң «үлемнәр, хезмәткә сәләтле яшьтәге халыкның үлү, балаларның үлү санын киметергә» сүзләрен өстәргә;

тугызынчы абзацта «һәм, дәүләт заказын саклап калган килеш, медицина персоналын эзлекле рәвештә хосусый практикага күчерү» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлектәге абзацлар өстәргә:

«3-1.3.0.10 Барлык гражданнарга да кимендә ике елга бер мәртәбә профилактик медицина тикшерүе үткәрүне тәэмин итәргә.

3-1.3.0.11 Халыкның (шул исәптән ерактагы җирләрдә урнашкан торак пунктларда яшәүчеләрнең) беренчел медицина-санитария ярдәмен күрсәтүче медицина оешмаларыннан оптималь файдалана алуын тәэмин итәргә, гражданнарның әлеге медицина оешмаларына мөрәҗәгать иткәндә чиратта тору вакытын киметергә, табибка язылу процедурасын гадиләштерергә.

3-1.3.0.12 Медицина хезмәт күрсәтүләре экспорты күләмен арттыруны тәэмин итәргә.

3-1.3.0.13 Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру системасын камилләштерергә.»;

«Гамәлләр юнәлешләре» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«• халык саны 2 мең кешегә кадәр булган торак пунктларда табиб амбулаторияләре, фельдшерлык һәм фельдшер-акушерлык пунктларын төзү ихтыяҗын, шулай ук халык саны 100 кешедән кимрәк булган торак пунктларда мобиль медицина комплексларыннан файдалануны исәпкә алып, сәламәтлек саклау өлкәсендә геомәгълүмат системасын кулланып, сәламәтлек саклауның беренчел буын медицина оешмалары челтәрен булдыру;

• «Татарстан Республикасында электрон сәламәтлек саклау» (ЕГИС ЭЗ РТ) бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә бердәм региональ цифрлы контурны булдыру исәбенә Татарстан Республикасында сәламәтлек саклау системасының эшләү нәтиҗәлелеген арттыру һәм сәламәтлек саклау өлкәсендә бердәм дәүләт

мәгълүмат системасына (ЕГИСЗ) интеграцияләнгән ЕГИС ЭЗ РТ нигезендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының ведомство буйсынуындагы дәүләт медицина оешмаларының мәгълүмати үзара эшләве механизмнарын оештыру, пациентның шәхси кабинетында электрон хезмәт күрсәтүләрне (сервисларны) гамәлгә ашыру;

● иртә диагностикалау һәм пациентлар сәламәтлеге торышын дистанцион мониторинглау системасын да кертеп, инновацияле медицина технологияләрен гамәлгә кертү;

● медицина хезмәткәрләренә өзлексез белем бирү системасын гамәлгә кертүне дә кертеп, шул исәптән дистанцион белем бирү технологияләреннән файдаланып, сәламәтлек саклау системасы оешмаларын квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү;

● медицина ярдәме сыйфатын арттыру максатларында клиник рекомендацияләрне һәм дәвалау беркетмәләрен гамәлгә кертү һәм алардан медицина ярдәменә түләү өчен файдалану;

● онкология авыруларына, йөрәк-кан тамырлары авыруларына каршы көрәш программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, балаларга медицина ярдәме күрсәтүнең заманча инфраструктураларын булдыруны да кертеп, балалар сәламәтлеген саклауны үстерү;

● пациентлар хокукларын яклау системасын булдыру;

● медицина хезмәт күрсәтүләре экспорты механизмын камилләштерү;

● амбулатория-поликлиника ярдәмен күрсәткәндә хроник авырулардан интегүче гражданнарны дарулар белән тәэмин итүне гамәлгә ашыру.»;

3.1.4 пунктның «Гамәлләр юнәлешләре» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гамәлләр юнәлешләре:

1) мәдәниятнең һәм сәнгатьнең дәүләт секторын ныгыту:

● дөньякүләм дәрәҗәдәге мәдәният эшлеклеләре һәм иҗат коллективлары өчен грантлар системасын үстерү: Татарстан арт-брендлары;

● һөнәр алу алдыннан һәм һөнәри белем бирү системасын үстерү;

● торышы канәгатьләнерлек булмаган һәм заман таләпләренә җавап бирми торган мәдәният учреждениеләрен мәдәният эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартларына туры килерлек итеп реконструкцияләү;

● заманча мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып, мәдәният өлкәсендә яңа төр хезмәтләр күрсәтүне популярлаштыру һәм тәкъдим итү;

● мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре хезмәтләре күрсәтүнең сыйфатын яхшырту һәм аларны төрлеләндерү өчен хокукый һәм икътисадый шартлар тәэмин итү;

● балалар музыкаль, сәнгать, хореография мәктәпләрен, училищеларын һәм сәнгать мәктәпләрен кирәкле инструментлар, җиһазлар һәм материаллар белән тәэмин итү;

● халык саны 500 мең кешегә кадәр булган торак пунктларда урнашкан кино залларында милли кинофильмнар күрсәтү өчен шартлар тудыру;

● ихтыярый ярдәм итү хәрәкәтләренә ярдәм күрсәтү, шул исәптән Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирасын саклау өлкәсендә дә;

2) мәдәният һәм туризм өлкәсе кооперациясен үстерү:

● гомуми һәм өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары, мәдәният һәм туризм учреждениеләре кооперациясе һәм интеграциясе өчен хокукый һәм икътисадый шартлар тәэмин итү;

● мәдәни туризм маршрутларының киң спектрын булдыру һәм тарату, мәгълүмат-туризм үзәкләре челтәрен, Татарстанның мәдәни мирасын һәм арт-брендларын капитализацияләү өчен нәтиҗәле маркетинг һәм логистика оештыру;

● визит-үзәкләр челтәрен арттыру;

● Татарстанның мәдәният учреждениеләре буенча виртуаль турлар оештыру өчен мәгълүмат технологияләреннән файдалану;

● күчмә мәдәният-мәгълүмат комплекслары эшчәнлеген тәэмин итү, гастроль эшчәнлегенә финанс ярдәме күрсәтүне арттыру;

● виртуаль концерт залы булдыру;

● төбәк һәм муниципаль яшь тамашачы театрларын һәм курчак театрларын аларны реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм техник яңадан җиһазлау юлы белән модернизацияләү;

● авыл җирлекләре территорияләрендә клуб тибындагы мәдәни-күңел ачу оешмалары эшчәнлегенә ярдәм итү һәм муниципаль китапханәләрне үстерүне тәэмин итү;

● Татарстан Республикасының Милли электрон китапханәсен үстерү;

● тулыландырылган чынбарлык форматында цифрлы гидлар белән җиһазландырылган виртуаль күргәзмә проектларын булдыру;

● балаларның һәм яшьләрнең ял итү һәм аларны сәламәтләндерү учреждениеләрен, шул исәптән яшьләр үзәкләрен һәм креатив пространстволарны реконструкцияләү һәм төзү;

● Россия һәм чит илләр кинокомпанияләре өчен инвестицияләр җәлеп итүне арттыру инструменты буларак, Татарстан Республикасы территориясендә кино эшчәнлегенә тотылган чыгымнар өлешен кире кайтару төрендәге кино эшчәнлегенә һәм телевидение эшчәнлегенә ярдәм итүнең төбәк чаралары системасын гамәлгә кертү;

3) креатив кластер булдыру.»;

3.1.5 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.5. Халыкны эш белән тәэмин итү, хезмәт җитештерүчәнлеге. Социаль яклау»;

«Төп мәсьәләләр» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«● түбән хезмәт җитештерүчәнлеге һәм хезмәт җитештерүчәнлегендә чит ил конкурентларыннан калышу.»;

«Максатчан күзаллау һәм бурычлар» бүлегендә:

беренче абзацта «хезмәт базары,» сүзләреннән соң «хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру,» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3-1.5.0.4 Эшче көчләрне нәтиҗәлерәк файдалану максатында халыкның территориаль мобильлегенә һәм республика чикләрендә хезмәт миграциясенә булышлык итәргә.»;

сигезенче абзацта «, шулай ук өлкәннәрне компьютерда эшләү нигезләренә өйрәтү» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«3-1.5.0.8 Икътисадның чимал булмаган төп тармакларының урта һәм эре предприятиеләрендә елына кимендә 5 процент күләмендә хезмәт җитештерүчәнлеге үсешен тәэмин итәргә.»;

«Гамәлләр юнәлешләре» бүлегендә:

«Зарури гамәлләр» блогына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«● предприятиеләрне хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүгә һәм төп фондларны модернизацияләүгә стимуллаштыру;

● хезмәт җитештерүчәнлеге үсешен тоткарлый торган норматив-хокукый һәм административ чикләүләрне киметү;

● предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүгә методик һәм оештыру ярдәме системасын булдыру;

● хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү нигезләрен өйрәтүгә, шул исәптән цифрлы технологияләрдән һәм платформа чишелешләреннән файдалану ярдәмендә дә, юнәлдерелгән кадрлар әзерләү системасын булдыру,»;

«Халыкны эш белән тәэмин итүнең территориаль программалары өчен финанслау проектын гамәлгә ашыру программасы» блогында «2014 – 2020 елларга» сүзләрен «2014 – 2021 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

«Социаль яклау өлкәсендә» блогына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«● күпбалалы гаиләләргә ярдәм чаралары исемлеген киңәйтү, шул исәптән күпбалалы гаиләләр өчен җир кишәрлекләрен инженерлык инфраструктурасы белән тәэмин итү.»;

«Аз керемле гаиләләрдән булган балалар өчен пособиеләр» проекты» блогында «2014 – 2020 елларга» сүзләрен «2014 – 2021 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

3.1.6 пунктның 3.1.6.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.6.2. «Белем алучы регион: яңа икътисадка – яңа һөнәрләр һәм күнекмәләр»

Проектның максаты – Татарстан Республикасының кадрлар потенциалын арттыруны тәэмин итә торган төп фактор буларак өлкәннәрнең өзлексез белем алу системасын үстерү.

Проект түбәндәгеләрне үз эченә ала:

● республиканың югары технологияле тармаклары (нефть химиясе, авиа-, автомобиль төзелеше) хезмәткәрләре өчен өзлексез белем бирү инфраструктурасын үстерүне;

● инвалидлар һәм сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен формаль һәм формаль булмаган белем бирүнең төрле рәвешләреннән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне;

● пенсия яшенә җитеп килүче һәм пенсия яшендәге затлар өчен массакүләм белем бирү һәм укыту программаларын башлап җибәрүне («Татарстанның көмеш еллар университеты»);

● Казанны Learning Cities халыкара ассоциациясенә кертүне, ЮНЕСКО тарафыннан үткәрелә торган белем алучы шәһәрләрнең халыкара рейтингларында катнашу.

● бөтен теләк белдерүчеләрнең цифрлы икътисад һәм хезмәт җитештерүчәнлеге өлкәсендәге компетенцияләрне үзләштерүен дә кертеп, эшләүче гражданнарның үз һөнәри белемнәрен өзлексез яңарту һәм алар тарафыннан яңа һөнәри күнекмәләр алу системасын булдыру;

● гражданнарга һөнәри үсеш һәм карьера үсеше өчен мөмкинлекләр бирү максатында һөнәри конкурслар системасын формалаштыру;

● остазлыкны үстерү, җәмәгать инициативаларына һәм проектларына ярдәм итү өчен шартлар тудыру;

● барлык төрдәге һәм баскычлардагы белем бирүнең югары сыйфатын һәм һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итә торган заманча һәм цифрлы белем бирүнең имин мохитен булдыру.

Көтелә торган нәтиҗә:

● регионның инвестицион җәлеп итүчәнлеген күтәрү, регионның инновацион икътисады өчен кеше капиталын алдан үстерү;

● республикадагы өлкәннәрнең функциональ (мәгълүмати, технологик, тел, финанс, медиа һәм башка төрләр) грамоталылыгын яхшырту;

республика халкының социаль җаваплылыгын арттыру һәм инвалидларны, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затларны, пенсия яшенә җитеп килүче һәм пенсия яшендәге затларны белем алу һәм әзерләү аша социаль адаптацияләү.»;

б) 3.2 бүлекчәдә:

3.2.1 пунктта:

«Татарстан Республикасы пространствосының көчле һәм йомшак яклары» бүлегенең «Йомшак яклар һәм проблемалар» блогында:

җиденче абзацта «; Татарстан Республикасының берничә чик буе районында күрше төбәкләрнең хуҗалык элементләре системасына интеграцияләүгә ориентлашу» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«муниципаль берәмлекләрнең авыл җирлекләре һәм ераклашкан территорияләр белән икътисадый бәйлелеген тәэмин итүче инфраструктураның начар үсеше.»;

3.2.2 пунктта:

«2030 елда Татарстанның пространство үсешен максатчан күзаллау» бүлегендә:

сигезенче абзацта «хәрәкәте» сүзеннән соң «һәм йөк ташу» сүзләрен өстәргә;

унынчы – уникенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ц-2.9 Сыйфатлы торак пространствосы һәм уңайлы шәһәр мохите үсә.

З-2.0.0.1 Фаразлана торган саны 4 182 мең кешеl булачак (2013 ел белән чагыштырганда 350 мең кешегә артык) республика халкын тормыш эшчәнлегенең сыйфатлы пространствосы һәм дүртенче технологик торышның булган ресурсла-

рыннан файдаланууга, 2030 елга кадәр алтынчы торышка күчү перспективасы белән 2020 елга бишенче торыштагы эшчәнлеккә актив күчүгә бәйле эшчәнлек өлкәләрендә эш белән тәэмин итәргә.

3-2.0.0.2 Транспорт-коммуникация системасының сыйфатын арттырырга. Транспорт-коммуникация системасы пассажирларның күчеп йөри алуын тәэмин итәргә тиеш: торак һәм эшлекле районнар эчендә – 30 минут эчендә; агломерацияләрнең үзәк эшлекле районнарында (үзәкләрендә) – 0,5–1 сәгать эчендә; агломерациянең үзәк эшлекле районнары (үзәкләре) арасында – 1,5–2 сәгать эчендә; күрше регионнарның агломерацияләре үзәкләре белән – 3–4 сәгать эчендә; транспортның төрле төрләрендә Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләре белән – 4–8 сәгать эчендә»;

түбәндәге эчтәлектәге унөченче һәм ундүртенче абзацлар өстәргә:

«3-2.0.0.3 Перспектив мәгълүмат технологияләрен кулланып, пространство белән идарә итүнең яңа дәрәҗәсенә күчәргә. Идарәнең яңа системасында пространствоның барлык структур элементлары һәм барлык кызыксынучы затлар күрсәтелергә, коллектив идарә итү методлары кертелергә тиеш.

3-2.0.0.4 Торак төзелеше күләмен арттырырга, гаиләләрне һәркем ала алырлык торак белән тәэмин итәргә, яшәү өчен яраксыз хәлдәге торак фондын тотрыклы кыскартуны тәэмин итәргә, шәһәр мохитенең уңайлылыгын кардиналь арттырырга һәм гражданнарның уңайлы шәһәр мохитен булдыруда турыдан-туры катнашуы механизмнарын үстерергә.»;

унөченче – утыз алтынчы абзацларны тиешенчә унбишенче – утыз сигезенче абзацлар дип санарга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«3-6.0.0.6 Эре сәнәгать үзәкләрендә атмосфера һавасының пычрану дәрәҗәсен киметүне тәэмин итәргә.

3-6.0.0.7 Халык өчен, шулай ук үзәкләштерелгән су белән тәэмин итүнең заманча системасы белән җиһазландырылмаган торак пунктларда яшәүчеләр өчен, эчәргә яраклы су сыйфатын яхшыртуны тәэмин итәргә.

3-6.0.0.8 Идел елгасын саклауны һәм аның пычрануын булдырмауны һәм уникаль су объектларын саклауны тәэмин итәргә.

3-6.0.0.9 Биологик төрлелекне саклауны һәм торгызуны тәэмин итәргә.

3-6.0.0.10 Калдыклар белән эш итү системасын камилләштерүне һәм тупланган зыян объектларын бетерүне тәэмин итәргә.

3-6.0.0.11 Сәнәгать предприятиеләрен модернизацияләү өчен шартлар тудырырга һәм ресурс нәтиҗәлелегенең (шул исәптән, энергетик) һәм экологик нәтиҗәлелекнең югары күрсәткечләре белән аерылып торучы җитештерү куәтләре төзелешен оештырырга.»;

«Гамәлләр юнәлешләре» бүлегендә:

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. экология үсеше:»;

түбәндәге эчтәлекле уникенче – егерме дүртенче абзацлар өстәргә:

«• түбәндәгеләрне кертеп, калдыклар белән эш итү системасын булдыру:

чүплекләрне юк итү һәм алар урнашкан территорияләрне торгызу, күмүе тыелган барлык җитештерү һәм куллану калдыкларын икенчел эшкәртү өчен шартлар тудыру;

санкцияләнмәгән чүплекләрне ачыклауга һәм юк итүгә юнәлдерелгән җәмәгать контроле системасын булдыру һәм аның нәтиҗәле эшләве;

калдыклар, шул исәптән I һәм II класслы хәвефлелектәге калдыклар белән имин эш итүне тәэмин итә торган заманча инфраструктура булдыру;

тупланган экологик зыян объектларын юк итү;

● эре сәнәгать үзәкләрендә пычраткыч матдәләр чыгаруны киметү чараларының комплекслы планнарын гамәлгә ашыру;

● әйләнә-тирә мохиткә сизелерлек тискәре йогынты ясый торган барлык объектлар тарафыннан иң яхшы мөмкин булган технологияләрдән файдалануга нигезләнгән экологик җайга салу системасын куллану;

● су әзерләүнең перспектив технологияләрен кулланып, су белән тәэмин итү системаларын модернизацияләү ярдәмендә эчәргә яраклы су сыйфатын яхшырту;

● уникаль су объектларын саклау, шул исәптән Идел елгасына җибәрелә торган агып төшүче пычранган сулар өлешен киметүгә юнәлдерелгән проектны гамәлгә ашыру;

● барлык дәрәҗәдәге махсус саклanuчы табигать территорияләре булган, урман белән капланган Татарстан Республикасы мәйданын арттыру;

● Татарстан Республикасында хайваннар дөньясы объектларын, су биологик ресурсларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау, торгызу һәм алардан рациональ файдалану;

● экологик тәрбия һәм белем бирүне, экология туризмын популярлаштыру;

● әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны булдырмау яисә минимальләштерү максатларында хуҗалык итү эшчәнлеген һәм башка, шул исәптән күздә тотылган эшчәнлекне, дәүләт җайга салуы нәтиҗәлелеген арттыру;»;

уникенче абзацны егерме бишенче абзац дип санарга;

түбәндәге эчтәлектәге абзацлар өстәргә:

«6. торак пространствосын һәм шәһәр мохитен үстерү, шул исәптән:

● төзелеш тармагын модернизацияләү һәм торак төзелеше сыйфатын яхшырту, шул исәптән искергән технологияләрне куллануга чикләүләр билгеләү һәм проектлауда, төзелештә алдынгы технологияләрне гамәлгә кертүне кызыксындыру ярдәмендә дә, стандарт торак төзелешенә дәүләт ярдәме механизмнарын камилләштерү;

● торак төзелешен финанслау механизмнарын камилләштерүдә катнашу, шул исәптән ипотека кыйммәтле кәгазьләре базарын үстерү һәм күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өчен акчалар җәлеп итүдән гражданнар хокукларын яклауны һәм алар өчен куркынычларны киметүне тәэмин итә торган торак төзелешен финанслауның башка рәвешләренә этаплап күчү ярдәмендә дә;

● төзүчеләргә административ басымны киметү, торак төзелеше өлкәсендә норматив-хокукый базаны һәм җайга салу тәртибен камилләштерү;

● яшеллек фондын һәм экологик, тарихи-мәдәни, рекреация, савыктыру һәм башка төр әһәмияткә ия табигать объектлары урнашкан территорияләрне саклап

калу һәм үстерү шартларында торак төзелеше максатлары өчен җирдән нәтиҗәле файдалануны тәэмин итү;

• Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр мохитенең уңайлы булуын кардиналь арттыру;

• яшәү өчен яраксыз булган торак фондын тотрыклы киметүне тәэмин итү;

• гражданнарга торак шартларын яхшыртуга ярдәм чараларын гамәлгә ашыру, гражданнарның федераль законда билгеләнгән категорияләрен һәм яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итүне дә кертеп;

• шәһәр мохитен үстерү мәсьәләләрен хәл итүдә катнаша торган гражданнар өлешен арттыру;

• төзелеш һәм шәһәр хуҗалыгы өлкәсендә урта һөнәри белем бирүне үстерү, шулай ук архитектура өлкәсендә белгечләрнең квалификацияләрен күтәрү программаларын гамәлгә ашыру.»;

3.2.3 пунктта:

3.2.3.1 пунктчасының икенче абзацына түбәндәге эчтәлектәге җөмлә өстәргә: «Икътисадый зоналар пояслары үзәкләрен булдыру территорияләр бәйләнешен арттырырга һәм Татарстан Республикасының ерактагы муниципаль берәмлекләре үсешен тәэмин итәргә ярдәм итәчәк.»;

3.2.3.2 пунктчасындагы «Кама агломерациясе» бүлегенең «Үзгәрешләр юнәлешләре» блогына түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

« • Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 17 июнендәге 1257-р номерлы карары белн расланган «ИнноКам» территориаль яктан аерымланган инновацияле җитештерү үзәген төзү концепциясенең өстенлекле проектларын гамәлгә ашыру»;

3.2.3.3 пунктчасының «Авыл җирлекләре территорияләрен үстерү концепциясе» блогының уникенче абзацында «хосусый» сүзен төшереп калдырырга;

3.2.3.5 пунктчада:

3.2 таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«3.2 нче таблица. Татарстан Республикасында тизйөрешле элемтәләр системасын булдыру гамәлләренең җыелма таблицасы – Минимум планы**

| Чират | Гамәл |
|---|---|
| Беренче чират – 2020 ел | Мәскәү – Казан ВСМын төзү |
| | М-7 автомобиль юлын (барлык участокларын) реконструкцияләү |
| | Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрен әйләнеп уза торган участокта Кама елгасы аша күпер кичүе белән «Волга» М-7 автомобиль юлын төзү һәм төзекләндерү |
| | «Казан шәһәрендә боҗралы тимер юл хәрәкәтен оештыру» проектын гамәлгә ашыру |

| Чират | Гамәл |
|---|---|
| Исәпләнгән вакыт – 2020 – 2030 еллар | Шәле – Баулы (Европа – Көнбатыш Кытай) автомобиль юлы, I чират |
| | Казан – Чаллы ВСМын төзү («Тихоново» станциясе) (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең тиешле карары булганда) |
| | Сөйки Кичүе (Кама Тамагы муниципаль районы) – Болгар паром кичүе |
| | «Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖ резидентларына хезмәт күрсәтү өчен «Тракторная» станциясеннән «Тихоново» станциясенә кадәр гомуми файдаланудагы яңа тимер юл төзү |
| | Круглое поле – Тихоново – Әгерҗе тимер юлының икенче төп юлларын төзү, электр үткәреп |
| | «Каратун» станциясеннән «Сөйки» авылына кадәр гомуми файдаланудагы тимер юл тармагын төзү |

»;

3.3 таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«3.3 нче таблица. Татарстан Республикасында тизйөрешле элемтәләр системасын булдыру гамәлләренең җыелма таблицасы – Максимум планы**

| Чират | Гамәл |
|---|---|
| 2020 елдан башлап регионара юлларны үстерү (күрше регионнар һәм Россия Федерациясе Транспорт министрлыгы белән килештереп) – 2030 елга кадәр проектлау һәм төзи башлау, 2030 елдан соң төзелешне тәгәлләү | Р-241 Казан – Ульяновск автомобиль юлы |
| | А-295 Казан – Йошкар-Ола автомобиль юлы |
| | Алексеевск – Высокий Колок – Самара автомобиль юлы |
| | «Европа – Көнбатыш Кытай» халыкара транспорт маршрутына кергән «Мәскәү – Түбән Новгород – Казан» тизйөрешле автомобиль юлын төзү, Идел елгасы аша күпер кичүе белән (Казан шәһәрен көньяктан урап узып) (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең тиешле карары булганда) |
| Исәпләнгән вакыт тәмамлангач (2030 елдан соң) | Казанны төньяктан әйләнеп узучы автомобиль юлы |
| | Идел елгасы аша күпер кичүе белән Буа – Тәтеш – Болгар – Әлмәт көньяк Татарстан магистрале |
| | «Южная» автомобиль юлында «Предкомбинатская» станциясе районында ике юл тармагын төзү |
| | Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авылы янында Ык елгасы аша күпер төзү |

| | |
|---|---|
| | Әлмәт – Чаллы автомобиль юлын реконструкцияләү |
| | «Чиста юл» автомагистрале |
| | Казан – Малмыж – Пермь автомобиль юлының Татарстан Республикасы территориясендәге участогы |
| | «АлаБег» проекты: Түбән Кама – Чаллы автомобиль юлы; «Бегишево» аэропорты – Алабуга – «Алабуга» МИЗ автомобиль юлы; Кама елгасы аша күпер, «АлаБег» – ЛРТ тизйөрешле элемтәсе |
| | Р-239 автомобиль юлын реконструкцияләү |
| | Казанны әйләнеп узучы йөк тимер юлы |
| Россия Федерациясе Транспорт министрлыгы, РЖД белән килештереп, 2020 елдан соң ВСМ системасын үстерү. Шул исәптән ВСМ линиясенә эре шәһәрләрне һәм күрше регионнарны (Марий Эл Республикасын һәм Удмурт Республикасын, Ульяновск өлкәсен) гамәлдәге тимер юл линияләрен реконструкцияләү юлы белән, алар буенча «эре шәһәр/регион үзәге – ВСМ терминалы» арасында тизләтелгән регионара пассажир поездлары йөрүне тәэмин итү өчен, тоташтыру | Казан – Екатеринбург ВСМ төзү |
| | Волжск – Зеленодольск – Казан (ВСМ терминалы) –Арча тимер юл линиясен реконструкцияләү (Казан агломерациясе шәһәрләренең Казандагы ВСМ терминалы белән тизләтелгән тимер юл элемтәсен оештыру) |
| | Зеленодольск – Йошкар-Ола тимер юлын реконструкцияләү (Марий Эл Республикасының Казандагы ВСМ терминалы белән тизләтелгән тимер юл элемтәсен оештыру) |
| | Зеленодольск – Буа – Ульяновск тимер юлын реконструкцияләү (Ульяновск өлкәсенең Казандагы ВСМ терминалы белән тизләтелгән тимер юл элемтәсен оештыру) |
| | Писмәнкә (Лениногорск шәһәре) – Әлмәт – Чаллы–Тихоново ВСМ терминалы – Әгерҗе – Ижевск тимер юлын реконструкцияләү (Удмурт Республикасының, Әлмәт агломерациясенең Тихоноводагы ВСМ терминалы белән тизләтелгән тимер юл элемтәсен оештыру) |

»;

в) 3.3 бүлекчәсендә:

3.3.2 пунктның «Гамәлләр юнәлешләре» бүлегендә:

түбәндәге эчтәлекле яңа унтугызынчы – егерме беренче абзацлар өстәргә:

«• үзмәшгуль гражданнар эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен уңайлы шартлар тәэмин итү;

• экспорт күләмен, шул исәптән, Татарстан җитештерүчеләренең чит илләр базарларына чыгу зоналарын киңәйтү өчен шартлар тудыру, республиканың Россия Федерациясе субъектлары һәм чит дәүләтләр белән экспорт эшчәнлеге өлкәсендә багланышларын ныгыту юлы белән, чимал булмаган продукция экспортын артуны тәэмин итү;

• экспортка ярдәм инфраструктурасының нәтиҗәлелеген арттыруны тәэмин итү, дәүләт органнары һәм эшкуарлык субъектларының экспортны үстерү мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек механизмнарын камилләштерү;»

унтугызынчы – кырык җиденче абзацларны тиешенчә егерме икенче – илленче дип санарга;

түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

« • фермерларга ярдәм системасын булдыру һәм авыл хуҗалыгы корпорациясен үстерү;

• авылда яшьләр эшкуарлыгын үстерү.»;

3.3.3 пунктның «Гамәлләр юнәлешләре» бүлегендә:

алтынчы абзацка «, шул исәптән аерым икътисадый зоналар, социаль-икътисадый үсеш алга киткән территорияләр, индустриаль парклар, муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданнары, технопарклар, инжиниринг үзәкләре һәм башка объектлар белән» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлектәге яңа утыз беренче абзац өстәргә:

«• төбәк икътисадына чит ил инвестицияләрен җәлеп итү һәм аның инвестицион климатын яхшырту мөмкинлеген бирә торган заманча төп финанс инструментларын куллану механизмнарын һәм өлкәләрен эшләү (дәүләти-хосусый партнерлык (концессия), ислам финанслары, корпоратив финанслар, блокчейн, «BigData» зур күләмле мәгълүматларны эшкәртү технологиясе, краудфандинг һәм башкалар).»;

утыз беренче һәм утыз икенче абзацларны тиешенчә утыз өченче һәм утыз дүртенче абзацлар дип санарга;

3.3.4 пунктта:

«Максатчан күзаллау һәм бурычлар» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле яңа бишенче абзац өстәргә:

**«Ц-5.4 Реаль секторда һәм социаль өлкәдә цифр технологияләре кертү.»;**

бишенче – тугызынчы абзацларны тиешенчә алтынчы һәм унынчы абзацлар дип санарга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«*З-5.0.0.6* Татарстан Республикасында һәрбер икътисадый актив гражданин цифр технологияләрен белә торган, ә дәүләт һәм бизнес югары цифрлы компетенцияләргә ия булган һәм аларны үз эшчәнлекләрендә системалы куллана торган цифрлы икътисад үсешен тәэмин итәргә.»;

«Гамәлләр юнәлешләре» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

***«Гамәлләр юнәлешләре:***

1) «Кеше капиталы» юнәлеше буенча:

• инновация системасы өчен кадрларны җәлеп итү, әзерләү, камилләштерү һәм эш урынында саклап калу: югары уку йортларында – галимнәрне/тикшерүчеләрне, эшкуарларны, инновацияләргә ярдәм итү өлкәсе белгечләрен, һөнәри белем бирү системасында – МСП һәм эре бизнес ихтыяҗлары өчен техник белгечлекләр кадрларын, предприятиеләрдә системалы рәвештә укытучылар составының озак вакытлы стажировкаларын оештыру;

• икътисадый зоналарны, агломерацияләрне үстерү проектларын гамәлгә ашырганда нәтиҗәле миграция агымнарын тәэмин итү кысаларында гамәлгә

ашырыла торган инновация проектларын төбәкнең хезмәт ресурсларының бердәй белешмәләр базасын кулланып, хезмәт ресурслары белән тәэмин итү;

2) «Киңлекләр, реаль капитал» юнәлеше буенча:

• инновация фирмаларына бизнес алып бару өчен уңайлы шартлар булдыру һәм аларның фирмаара элемтәләрен һәм хезмәттәшлекләрен стимуллаштыру максатларында инновация инфраструктурасын (технопарклар, технополислар) алга таба үстерү;

• төбәктә эшләүче белгечләр өчен югары тормыш сыйфатын тәэмин итә торган комплекслы инфраструктура булдыру һәм аңа ярдәм итү, шулай ук инновацияләрне тизләтелгән рәвештә булдыру һәм кертү өчен шартлар тудыру;

3) «Базарлар» юнәлеше буенча:

• товарларның, хезмәт күрсәтүләрнең, технологияләрнең, капиталның һәм кадрларның тышкы базарлары белән актив хезмәттәшлекне тәэмин итү;

• инновация компанияләренең халыкара югары технологияле продукция базарына чыгуына мәгълүмати һәм консультатив ярдәм итү;

• инновацияле компанияләр экспортына һәм халыкара фирмаара бәйләнешләрне үстерүгә дәүләт ярдәме күрсәтү;

• инновацияләрне икътисадый яктан стимуллаштыру;

• җитештерелә торган инновацияләрнең эчке һәм тышкы базарларда кирәклеген һәм конкурентлылыкка сәләтле булуын өстенлекле тармаклар/кластерлар буенча тәэмин итү (продуктлар, хезмәтләр, технологияләр);

4) «Институтлар» юнәлеше буенча:

• дәүләтнең директив катнашуыннан башка тышкы факторларга тотрыклылыкны тәэмин итә торган формаль һәм формаль булмаган эчке институтлар үсешен стимуллаштыру;

• Татарстан Республикасында яшәүче һәр кеше күзлегеннән конкрет файда тасвирланышы белән инновацияле үсеш логикасын популярлаштыру;

• җәмгыятьтә ышаныч һәм челтәр хезмәттәшлеге дәрәҗәсен арттыруны стимуллаштыру;

• инновация процессында барлык катнашучылар өчен дә билгеле һәм аңлаешлы булган үтәкүренмәле эш кагыйдәләрен формалаштыру һәм аның сакланышын тәэмин итү;

• экосистеманың барлык катнашучылары өчен ачык хезмәттәшлек һәм кире элемтә мөмкинлеген тәэмин итү;

• экосистема эшенең даими һәм ачык мониторингын стимуллаштыру;

• Татарстан Республикасының инновацияле үсеш институтын формалаштыру (Стратегияне гамәлгә ашыруның икенче этабында);

• хәвефкә һәм уңышсызлыкларга – тотрыклы инновацияле үсешнең төп факторларына толерантлык дәрәҗәсен арттыру;

• Татарстан Республикасында фәнни һәм инновацияле эшчәнлекне популярлаштыру;

5) «Финанс капиталы» юнәлеше буенча:

• инновация процессының барлык стадияләрендә дә «акыллы» акчаларны җәлеп итүгә йөз тоткан шәхси кертемнәр өстенлек алган финанслау системасын формалаштыру;

• шәхси венчур фондлары һәм «бизнес-ангеллар» үсешенә булышлык итү;

• социаль әһәмияткә ия яки башка социаль проектлардан кала, дәүләт кертемнәре өлешен киметүне стимуллаштыру;

б) «Цифрлы икътисад» юнәлеше буенча:

• цифрлы икътисад өчен югары квалификацияле кадрлар әзерләүне тәэмин итү;

• цифрлаштыру процессы өчен инфраструктура нигезен тәэмин итү: белешмәләрне тапшыруның, эшкәртүнең һәм саклауның үз илебез эшләнмәләре нигезендәге глобаль конкурентлылыкка сәләтле инфраструктурасын булдыру;

• Татарстан Республикасының цифрлы инфраструктурасының тотрыклы эшчәнлеген тәэмин итү;

• белешмәләрне тапшырганда, эшкәрткәндә һәм саклаганда шәхес, бизнес һәм дәүләт мәнфәгатьләрен саклауны гарантияли торган үз илебез эшләнмәләре нигезендә мәгълүмати куркынычсызлык тәэмин итү;

• өстенлекле рәвештә үзебезнең эшләнмәләр нигезендә бәйләнешле цифр технологияләре булдыру;

• дәүләт идарәсе һәм муниципаль идарә, хезмәт күрсәтүләр өлкәләрендә цифр технологияләрен һәм платформа чишелешләрен кертү хисабына дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары эшенең, шул исәптән, индивидуаль эшкуарларны да кертеп, халык һәм кече, урта эшкуарлык субъектлары мәнфәгатьләрендә нәтиҗәлелеген арттыру;

• икътисад өлкәсенең һәм социаль өлкәнең өстенлекле тармакларын, сәламәтлек саклауны, мәгарифне, сәнәгатьне, авыл хуҗалыгын, төзелешне, шәһәр хуҗалыгын, транспорт һәм энергетика инфраструктурасын, финанс хезмәтләре күрсәтүне кертеп, цифр технологияләрен һәм платформа чишелешләрен кулланып яңарту;

• икътисадның реаль сектор предприятиеләрен цифр технологияләрен һәм платформа чишелешләрен комплекслы кертүгә стимуллаштыру;

• гражданнарның цифрлы грамоталылык дәрәҗәсен, шулай ук предприятиеләрнең, оешмаларның, дәүләт һм муниципаль учреждениеләрнең цифрлы компетенцияләрен күтәрү;

• ИТ-аутсорсинг базарында Татарстанның лидерлык позицияләрен тәэмин итү.»;

3.3.5 пунктта:

«Максатчан күзаллау һәм бурычлар» бүлегендә:

3.32 рәсемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

# Татарстан-2017 – 2020 – 2030 – региональная кластерная активация

Конвергенция кластеров современной и «Умной» экономики (второй этап: 2017 – 2020 гг. — выстраивание кластерной системы — организационная фаза, третий этап: 2020 – 2030 гг. — активная фаза)

**Сокращения**

НГХК Нефтегазохимический комплекс
ЭК Энергетический комплекс
АПК Агропромышленный комплекс
МК Комплекс машиностроения и другой обрабатывающей промышленности

Ключевые кластеры

Инновационные кластеры «Умной» экономики

Кластеры современной экономики




*Субкластеры АПК: молочный, мясной, сахарный, масложировой,зерновой, овощной, картофельный, плодово-ягодный, аквакультура

**3.32 нче рәсем. Татарстан Республикасы кластерлары (икенче һәм өченче этаплар)»;**

«Арадаш максатлар» блогына түбәндәге эчтәлекле унынчы абзац өстәргә:

«*3-4.2.0.8* Кластерлар предприятиеләренең инновацияле продукцияләренә ихтыяҗ формалаштыруны стимуллаштыру.»;

унынчы абзацны унберенче абзац дип санарга;

3.3.6 пунктта:

3.3.6.2 пунктчасының «Гамәлләр юнәлешләре» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә :

***«Гамәлләр юнәлешләре:***

1) Татарстан Республикасы икътисадының төп өлешләреннән берсе буларак, **энергетика комплексын нисбәтле үстерү**, шулай ук тулаем региональ икътисадның конкуренциягә сәләтлелеген**,** Татарстан Республикасы энергия системаларын генерацияләү чыганакларында яңа технологияләр куллану нигезендә конкурентлы бәяләр буенча кирәкле күләмдә энергия җитештерү, энергияне сак тотуның югары сыйфатын һәм ышанычлылыгын тәэмин итү;

2) «**Тотрыклы энергетика» инновацияле кластерын үстерү** (кара: 3.3.7.2).

Энергетика кластерында төп катнашучылар: «Татэнерго» АҖ, «ТГК-16» ААҖ, «Түбән Кама ТЭЦ» ҖЧҖ, «Челтәр компаниясе» ААҖ һәм Татарстан Республикасының гарантияле тәэмин итүчесе – «Татэнергосбыт» АҖ.»;

3.3.6.3 пунктчасында:

«Максатчан күзаллау» бүлегендә «агач эшкәртү һәм йорт җиһазы сәнәгатендә» сүзләрен «агач эшкәртү, йорт җиһазлары һәм композит сәнәгатендә» сүзләренә алмаштырырга;

«Гамәлләр юнәлеше» бүлегендә:

өченче абзацта «тиз йөрешле пассажир суднолары,» сүзләреннән соң «шул исәптән кысылган табигый газ ягулыгында эшләүче, панорама төрендәге прогулка-экскурсия пассажир суднолары, каюта тибындагы суднолар,» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлектәге абзацлар өстәргә:

«9) **композит сәнәгате:** сәнәгать өлкәсендә территориаль якынлык һәм функциональ буйсынганлык нәтиҗәсендә әлеге өлкәдә мөнәсәбәтләр белән бәйләнгән эшчәнлек субъектлары бергәлегеннән гыйбарәт «Чиксез композитлар» төбәкара сәнәгать кластерын булдыру һәм үстерү, Россия Федерациясенең сәнәгать продукциясе җитештерелә торган өч субъекты – Татарстан Республикасы, Мәскәү һәм Саратов өлкәләре территорияләрендә урнаштыру.

*Субкластерда төп катнашучылар*: «Интек»ҖЧҖ инжиниринг компаниясе, «Алабуга-Волокно» ҖЧҖ, «Композит-Волокно» ҖЧҖ, «РЕКОН» ФҖФ» ҖЧҖ, «РариТЭК Инжиниринг» ҖЧҖ, «КАМАТЕХ» ҖЧҖ, «Препрег-Дубна» ҖЧҖ, «М.П.Симонов исемендәге ОКБ» ФҖБ» АҖ, «НПЦ «УВИКОМ» ҖЧҖ, «Татнефть-Пресскомпозит» ҖЧҖ, «СМП-Механика» ҖЧҖ, «ИТЕКМА» ҖЧҖ, «Аргон» ҖЧҖ, «ЗАРЯД» ҖЧҖ, «Композит» ААҖ, «ЦНИИСМ» АҖ, «ЦПР АО ЦНИИСМ» АҖ, «П-Д Татнефть-Алабуга Стекловолокно» ҖЧҖ, НПП «Пыяла-пластик торбалар заводы» ҖЧҖ, «РМЗ «РариТЭК» ҖЧҖ, «Химград» АҖ, «Казан (Идел буе) федераль университеты» ФДАЮБМУ, «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты» ФДАЮБМУ, «Казан милли-тикшеренү технология университеты» ФДАЮБМУ, «Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖ, «Технология университеты» ФДАЮБМУ, «Дубна» университеты» («Дубна» дәүләт университеты) ФДАЮБМУ.»;

3.3.6.4 пунктчасының «Гамәлләр юнәлешләре» бүлегендә:

җиденче абзацта «Ваклап сату челтәрләре белән» сүзләрен «Федераль һәм дөнья сәүдәсе белән» сүзләренә алмаштырырга;

«АПК кластерында төп катнашучылар» блогында:

беренче – өченче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**Ашлык субкластеры**: «Союз Агро» ҖЧЖ, «Ак Барс»ХК» ААҖ төркеме предприятиеләре, «Кызыл Шәрык Агро» ААҖ, «Азнакай» агрофирмасы» ҖЧЖ, «Лениногорск» агрофирмасы» ҖЧЖ.

**Шикәр субкластеры**: Буа шикәр заводы («Ак Барс» ХК»ААҖ), Нурлат шикәр заводы («Агроинвест» идарәче компаниясе), Зәй шикәр заводы («Агросила» ЯАҖ). Чимал җитештерүчеләр: «Ак Барс» ХК» ААҖ төркеме предприятиеләре, «Агросила»ҖЧЖ холдинг компаниясе предприятиеләре («Зәй шикәре» агрофирмасы» ҖЧЖ).

**Май субкластеры**: «Нәфис Косметикс» төркеме предприятиеләре, шул исәптән «Казан май сыгу заводы» ААҖ (үсемлек мае җитештерү), «Казан май комбинаты» ААҖ (май продукциясе җитештерү), «Нәфис Косметикс» ААҖ (химия продукциясе җитештерү), «Эссен Продакшн АГ» ЯАҖ. Чимал җитештерүче төп предприятиеләр: «Восток Зернопродукт» ЯАҖ, «ВЗП Биләр» ҖЧЖ, «ВЗП Болгар» ААҖ»;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**Сөт субкластеры**: «Казан сөт комбинаты» ҖЧЖ, «Бөгелмә сөт комбинаты» ҖЧЖ, «Азбука сыра» ҖЧЖ (Мамадыш сыр-май комбинаты), «Агросила молоко» ҖЧЖ (Чаллы сөт комбинаты), «Данон» АҖ (Эдельвейс СК филиалы), «Зеленодольск сөт комбинаты» ААҖ, «Арча» ҖЧЖ (Балтач һәм Арча сөт заводлары), «Алабуга сөте» ААҖ, «Касымов сөт комбинаты» ҖЧЖ, «Биектау сөт комбинаты» ҖЧЖ, «Алексеевск сөт заводы» ҖЧЖ, «Слобода» ҖЧЖ, «Азнакай сөте» ҖЧЖ, «Югары Ослан» агрофирмасы» ҖЧЖ.»;

3.3.6.5 пунктчасында:

«**Инфраструктураны максатчан күзаллау**» бүлегенең беренче абзацында «Төзелеш һәм яңа төзелеш материаллары» кластеры» сүзләрен «Төзелеш кластеры» һәм «Төзелеш технологияләре һәм материаллары кластеры» кластерлары» сүзләренә алмаштырырга;

«Гамәлләр юнәлеше» бүлегендә:

өченче һәм дүртенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) **«Төзелеш кластеры» һәм «Төзелеш технологияләре һәм материаллары кластеры» кластерлары:**

Татарстанның инновацион төзелеш материаллары һәм технологияләре өлкәсендә лидер буларак, ә республика предприятиеләренең – глобаль инновацион төзелеш базарында әйдәп баручы катнашучылар статусында үсүе. Төзелеш комплексының кластер активлыгы, предприятиеләр кооперациясе һәм аларны берләштерү, производстволарны туплау, Татарстан Республикасы компанияләренең глобаль инновацион төзелеш базарына чыгуы һәм Россия Федерациясе территориясендә төзелеш проектларын гамәлгә ашыруда лидерлыкка ирешү.

*Төзелеш кластерында төп катнашучылар*: «Сувар Девелопмент» ҖЧЖ, «Юрист&Инженер» ҖЧЖ, «Төзелеш академиясе» ҖЧЖ, «Бәрәкәт» ҖЧЖ,

«Стройинвест» ҖЧҖ, «Витек-групп» ҖЧҖ, «Казан силикат стена материаллары заводы» ҖЧҖ, «Регион Климатика» ТК, «Альфа-тех» ҖЧҖ, «Альянс – Фасад конструкцияләре» ҖЧҖ, «Тракья Гласс Рус» АҖ, «Стройиндустрия» ҖК ҖЧҖ, «Россия Пыяла Компаниясе» ҖЧҖ, «РегалСтрой» ҖЧҖ, «АФК» ҖЧҖ, «Заманча автоматика» ҖЧҖ, «Навек» ҖЧҖ. *Төзелеш технологияләре һәм материаллары кластерында төп катнашучылар*: «Ак Барс Девелопмент» ҖЧҖ, «Казан өй төзү компаниясе» ҖЧҖ, «Ак Барс Инжиниринг» ҖЧҖ, «Архитектура бюросы-1» ҖЧҖ,«Витраж плюс» ҖЧҖ, «Компания Тантал» ҖЧҖ, «КСК» ҖЧҖ, «Окна Плюс» ҖЧҖ, «Полипласт-Казан» ҖЧҖ, «Полифлекс» ҖЧҖ, «СК Кама» ҖЧҖ,«Строй-пласт» ҖЧҖ, «Татсвязьсервис» ҖЧҖ, «ТК «Витек-Групп» ҖЧҖ»;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«*Төп катнашучылар*: «Водоканал» МУП, «Казэнерго» АҖ, «ПҖКХ» ҖЧҖ, «Уютный дом» ИК» ҖЧҖ, «Азнакай ПТС» ААҖ, «Әлмәт водоканалы» АҖ, «АПТС» АҖ, «Бөгелмә водоканалы» ҖЧҖ, «Бөгелмә ПТС» ҖЧҖ, «Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖ, «Алабуга ПТС» ААҖ, «Газпром теплоэнерго Казан» ҖЧҖ, «ЗВКС» АҖ, «Зеленодольск ПТС» ААҖ, «ЛТС» ҖЧҖ, «Ремжилстрой» ИК ҖЧҖ, «Чаллы водоканалы» ҖЧҖ, «Чаллы-лифт» ҖЧҖ, «Паритет» ИК ҖЧҖ, «ПКФ «Жилкомсервис» ҖЧҖ, «ПЭК» ҖЧҖ, «ВК и ЭХ» АҖ, «Нурлат җылылык челтәре» АҖ, «Чистай ПТС» ААҖ, «Чистай водоканалы» АҖ;»;

«Гамәлләр юнәлешләре» бүлегенең беренче һәм икенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) **«Финанс һәм һөнәри хезмәт күрсәтүләр» кластеры**: белемгә нигезләнгән югары җитештерүчән бизнес-хезмәт күрсәтүләрне алдан үстерү; финанс, инвестицион, иминият һәм башка һөнәри[1] хезмәт күрсәтүләрнең глобаль конкурентлыкка сәләтле базарын булдыру, бердәм дөнья киңлегенә кушылу аша «Казан – региональ финанс үзәге» кластер проектын үстерү; финанс һәм һөнәри хезмәт күрсәтүләргә халыкның һәм оешмаларның ихтыяҗларын максималь канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән нәтиҗәле оешкан система булдыру; махсуслаштырылган инновацион-инвестицион инфраструктураны үстерү. Татарстан икътисадында финанс секторының мөстәкыйль ролен акрынлап арттыру һәм аның кайбер сегментларын Россия эчендә дә, чит илләрдә дә махсуслаштыру предметына әверелдерү.

*Төп катнашучылар*: Банк секторы: «Ак Барс Банк» ААҖ, «Банк «Аверс» ҖЧҖ, «ТАТСОЦБАНК» АҖ, «Акибанк» ГАҖ, «Энергобанк» АКБ (ГАҖ), «Девон-Кредит» АБ (ГАҖ). Иминият секторы: «НАСКО» АҖ, «Талисман» ИҖ» АҖ, «Чулпан» ИК» АҖ, «АК БАРС СТРАХОВАНИЕ» ҖЧҖ, «Армеец» ИК» АҖ. Кыйммәтле кәгазьләр базары: «Татарстан Республикасы үзәк депозитарие» АҖ, «Евроазиат Регистраторы» ҖЧҖ, «Пилигрим» инвестиция-финанс компаниясе» ЯАҖ, «ТАИФ-ИНВЕСТ» ҖЧҖ, «АК БАРС КАПИТАЛ» идарәче компаниясе» ҖЧҖ, «Финам Зилант» ҖЧҖ, шулай ук профессиональ консультацияләр бирүче төбәк компанияләре;»;

3.3.7 пунктның 3.3.7.2 пунктчасында:

3.35 нче рәсемнән соң унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) **«Тотрыклы энергетика» инновацияле кластеры**. Заманча зур һәм бүленгән энергетиканың («акыллы» генерация һәм «акыллы» челтәрләр, яңа

аккумуляторлар һәм чыбыклар, һ.б), энергиянең тотрыклы чыганакларының (кояш энергиясе, су һәм җил энергияләре, атом энергиясе, биокалдыклар һәм көнкүреш калдыкларыннан алынган энергия) яңа технологияләрен куллану нигезендә инновацияле тотрыклы энергетиканы үстерү өчен уңайлы шартлар булдыру, шулай ук исәпкә алуның, биллингның интеллектуаль системаларын үстерү һәм энергия ресурсларын соңгы кулланучылар өчен бәя билгеләнешенең ачыклыгын арттыру;»;

түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«Биофармацевтика кысаларында «Биофармацевтика кластеры үсеше. «Татарстан Республикасының ФармМедПолисы» проекты гамәлгә ашырыла. Проектның максаты – Татарстан Репубикасының биофармацевтика сәнәгатен төп ике юнәлешкә басым ясап үстерү: фармацевтика производствосын Татарстан Республикасына икътисадый эшчәнлекне алып баруның аерым шартлары каралган мәйданнар (аерым икътисадый зоналар, социаль-икътисадый үсеш алга киткән территорияләр) резидентлары сыйфатында фармацевтика компанияләрен җәлеп итү хисабына алдан үстерү; Татарстан Республикасының гамәлдәге профильле фәнни-белем бирү учреждениеләре эшчәнлеген бергә туплау хисабына тикшеренү хезмәтләре күрсәтү күләмен арттыру һәм тикшеренүләр нәтиҗәләрен коммерцияләштерү.»;

4) 4 бүлектә:

а) 4.2 бүлекчәсендә:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3). Россия Федерациясенең ике һәм икедән артыграк субъектларын территориаль планлаштыру схемасы, әлеге схема проектын Татарстан Республикасы территориясенә яки территориянең өлешләренә карата әзерләгән очракта, Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы.»;

түбәндәге эчтәлекле яңа алтынчы абзац өстәргә:

«Моннан тыш, стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыру инструментларының берсе Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләренә халыкның яшәү сыйфатын һәм аларның эшчәнлек нәтиҗәсен бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт заданиесеннән (алга таба – дәүләт заданиесе) гыйбарәт. Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләренә бирелгән дәүләт заданиесе шулай ук Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затларының эшчәнлек нәтиҗәсен бәяләү өчен күрсәткечләргә ирешүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән.»;

алтынчы һәм җиденче абзацларны тиешенчә җиденче һәм сигезенче абзацлар дип санарга;

б) 4.3 бүлекчәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**4.3. Дәүләт программалары исемлеге**

Стратегия нигезендә Стратегияне гамәлгә ашыру максатларында тормышка ашырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт программалары җыелмасы төгәлләштерелде (4.1 нче таблица).

Гамәлдәге дәүләт программалары 2025 елга кадәр гамәлгә ашырыла (шул елны кертеп). Кирәк булганда аларга Стратегия максатлары һәм бурычлары

нигезендә үзгәрешләр кертеләчәк. Шулай ук тармак комплексларын үстерү бурычларын гамәлгә ашыру максатларында кайбер дәүләт программаларын эшләү күздә тотыла.

**4.1 нче таблица. Татарстан Республикасының гамәлдәге һәм эшләү, кабул итү планлаштырыла торган дәүләт программалары исемлеге**

| № п/п | Татарстан Республикасының гамәлдәге дәүләт программалары исемлеге | Татарстан Республикасының гамәлдәге дәүләт программалары тәгәлләнгәч кабул ителәчәк дәүләт программалары исемлеге | Стратегияне гамәлгә ашыру этаплары буенча гамәлдә булу чорлары | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2016 – 2018 | 2019 – 2021 | 2022 – 2024 | 2025 – 2030 |
| 1. | Татарстан Республикасында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру | | + | + | | |
| 2. | | Татарстан Республикасында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру | | | + | + |
| 3. | 2013 – 2021 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу | | + | + | | |
| 4. | | Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу | | | + | + |
| 5. | 2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы урман хуҗалыгын үстерү | | + | + | | |
| 6. | | Татарстан Республикасы урман хуҗалыгын үстерү | | | + | + |
| 7. | 2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү | | + | + | + | |
| 8. | | Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү | | | + | + |
| 9. | 2013 – 2023 елларга Татарстан Республикасында газ мотор ягулыгы базарын үстерү | | + | + | + | |
| 10. | | Татарстан Республикасында газ мотор ягулыгы базарын үстерү | | | + | + |

| № п/п | Татарстан Республикасының гамәлдәге дәүләт программалары исемлеге | Татарстан Республикасының гамәлдәге дәүләт программалары тәгәлләнгәч кабул ителәчәк дәүләт программалары исемлеге | Стратегияне гамәлгә ашыру этаплары буенча гамәлдә булу чорлары | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2016 – 2018 | 2019 – 2021 | 2022 – 2024 | 2025 – 2030 |
| 11. | 2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү | | + | + | | |
| 12. | | Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү | | + | + | + |
| 13. | 2021 елга кадәр Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү | | + | + | | |
| 14. | | Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү | | + | + | + |
| 15. | 2014 – 2021 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» | | + | + | | |
| 16. | | Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү | | | + | + |
| 17. | 2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү | | + | + | | |
| 18. | | Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү | | | + | + |
| 19. | 2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү | | + | + | + | + |
| 20. | | Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү | | | | + |
| 21. | 2015 –2020 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү | | + | + | | |
| 22. | | Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү | | + | + | + |
| 23. | 2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү | | + | + | | |
| 24. | | Татарстан Республикасында туризмны үстерү | | | + | + |

| № п/п | Татарстан Республикасының гамәлдәге дәүләт программалары исемлеге | Татарстан Республикасының гамәлдәге дәүләт программалары тәгәлләнгәч кабул ителәчәк дәүләт программалары исемлеге | Стратегияне гамәлгә ашыру этаплары буенча гамәлдә булу чорлары | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2016 – 2018 | 2019 – 2021 | 2022 – 2024 | 2025 – 2030 |
| 25. | 2014 – 2021 елларга «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» | | + | + | | |
| 26. | | Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү | | + | + | + |
| 27. | 2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культураны һәм спортны үстерү | | + | + | | |
| 28. | | Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культураны һәм спортны үстерү | | + | + | + |
| 29. | 2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында «Ачык Татарстан» мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү | | + | + | | |
| 30. | | Татарстан Республикасында «Ачык Татарстан» мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү | | + | + | + |
| 31. | 2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасын икътисадый үстерү һәм аның инновацион икътисады | | + | + | | |
| 32. | | Татарстан Республикасын икътисадый үстерү һәм аның инновацион икътисады | | + | + | + |
| 33. | 2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш | | + | + | | |
| 34. | | Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш | | + | + | + |
| 35. | 2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү | | + | + | | |

| № п/п | Татарстан Республикасының гамәлдәге дәүләт програм-малары исемлеге | Татарстан Республикасының гамәлдәге дәүләт программалары тәгәлләнгәч кабул ителәчәк дәүләт программалары исемлеге | Стратегияне гамәлгә ашыру этаплары буенча гамәлдә булу чорлары | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2016 – 2018 | 2019 – 2021 | 2022 – 2024 | 2025 – 2030 |
| 36. | | Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү | | | + | + |
| 37. | 2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында әйләнә-тирә мохитне саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану | | + | + | | |
| 38. | | Татарстан Республикасында әйләнә-тирә мохитне саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану | | | + | + |
| 39. | 2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү | | + | + | | |
| 40. | | Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү | | | + | + |
| 41. | 2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт финанс-лары белән идарә итү | | + | + | | |
| 42. | | Татарстан Республикасы дәүләт финанслары белән идарә итү | | | + | + |
| 43. | 2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үстерү һәм Татар-стан Республикасында муни-ципаль хезмәтне үстерү | | + | + | | |
| 44. | | Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үстерү һәм Татарстан Республикасында му-ниципаль хезмәтне үстерү | | | + | + |
| 45. | 2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашы-ру | | + | + | | |
| 46. | | Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру | | + | + | + |
| 47. | Татар халкының милли үзенчәлеген саклап калу (2014 – 2021 еллар ) | | + | + | | |

| № п/п | Татарстан Республикасының гамәлдәге дәүләт программалары исемлеге | Татарстан Республикасының гамәлдәге дәүләт программалары тәгәлләнгәч кабул ителәчәк дәүләт программалары исемлеге | Стратегияне гамәлгә ашыру этаплары буенча гамәлдә булу чорлары | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2016 – 2018 | 2019 – 2021 | 2022 – 2024 | 2025 – 2030 |
| 48. | | Татар халкының милли үзенчәлеген саклап калу | | + | + | + |
| 49. | 2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү | | + | + | | |
| 50. | | Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү | | + | + | + |
| 51. | 2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында юстицияне үстерү | | + | + | | |
| 52. | | Татарстан Республикасында юстицияне үстерү | | | + | + |
| 53. | 2015 – 2021 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру | | + | + | | |
| 54. | | Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру | | | + | + |
| 55. | 2016-2020 елларга Татарстан Республикасында товар аквакультурасын (товар балыкчылыгын) үстерү | | + | + | | |
| 56. | 2016-2020 елларга Татарстан Республикасында сәнәгатьнең эшкәртү тармакларын үстерү | | + | + | | |
| | | Татарстан Республикасында сәнәгатьнең эшкәртү тармакларын үстерү | | + | + | + |
| 57. | 2016-2021 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү | | + | + | | |
| 58. | | Татарстан Республикасында архив эшен үстерү | | | + | + |
| 59. | | Чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызга Татарстан Республикасына ихтыярый күчеп кайтырга булышу | | + | + | + |

| № п/п | Татарстан Республикасының гамәлдәге дәүләт программалары исемлеге | Татарстан Республикасының гамәлдәге дәүләт программалары тәгәлләнгәч кабул ителәчәк дәүләт программалары исемлеге | Стратегияне гамәлгә ашыру этаплары буенча гамәлдә булу чорлары | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2016 – 2018 | 2019 – 2021 | 2022 – 2024 | 2025 – 2030 |
| 60. | 2018 – 2022 елларга Татарстан Республикасы территориясендә заманча шәһәр мохитен формалаштыру | | + | + | + | |
| 61. | | Татарстан Республикасы территориясендә заманча шәһәр мохитен формалаштыру | | | + | + |
| 62. | 2019-2021 елларга Татарстан Республикасы территориясендә автомобильләргә газ салу станцияләре төзү | | | + | | |
| 63. | | Татарстан Республикасы территориясендә автомобильләргә газ салу станцияләре төзү | | | + | + |

»;

5) 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясенә 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2030 елга кадәр Татарстан<br>Республикасын социаль-икътисадый<br>үстерү стратегиясенә 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы икътисадый комплекслары структурасы**

Икътисадны «база икътисадый комплекслар – икътисадый комплекслар – тармаклар» вертикаль-интеграль система форматында структуралаштыру ОКВЭД 2 буенча башлангыч белешмәләр, шулай ук өстәмә аналитика нигезендә башкарыла. Мондый структура Татарстан Республикасы үсешенә идарә итү системасының яңа каркасын төзергә мөмкинлек бирәчәк.

Диагностика, максатлар кую, гамәлләрнең юнәлешләрен билгеләү Стратегиядә икътисадый комплекслар буенча башкарыла һәм тасвирлана. Икътисадый комплекслар буенча икътисад структурасы ОКВЭД 2 буенча икътисад структурасыннан бераз аерыла, бу аерымлык тармакка бәйле рәвештә кайбер комплексларда беренче, икенче һәм өченче тәртипләрдәге структур элементларның төркемнәргә берләштерелгән булуына бәйле.

## Таблица. ОКВЭД 2гә карата икътисадый комплекслар структурасы

| Икътисад структурасы: база икътисадый комплекслар – икътисадый комплекслар – тармаклар | ОКВЭД 2 тиешле бүлекләре |
|---|---|
| **Нефть-газ-химия комплексы** | |
| Ягулык-энергетика казылмаларын чыгару | В. Файдалы казылмалар чыгару:<br>06. Нефть чималын һәм табигый газ чыгару<br>09.1. Нефть һәм табигый газ чыгару өлкәсендә хезмәт күрсәтүләр |
| Нефть продуктлары җитештерү | С. Эшкәртү производстволары:<br>19.2. Нефть продуктлары җитештерү |
| Химия производствосы | С. Эшкәртү производстволары:<br>20. Химик матдиләр һәм химия продукциясе җитештерү<br>21. Дарулар һәм медицина максатларында кулланыла торган материаллар җитештерү |
| Резина һәм пластмасс әйберләр җитештерү | С. Эшкәртү производстволары:<br>22. Резина һәм пластмасс әйберләр җитештерү |
| Торбаүткәргеч транспорт | Н. Транспортировкалау һәм саклау:<br>49.5. Торбаүткәргеч транспорт эшчәнлеге |
| Газсыман ягулык җитештерү һәм бүлү | D. Электр энергиясе, газ һәм пар белән тәэмин итү; һаваны чистарту:<br>35.2. Газсыман ягулык җитештерү һәм бүлү |
| **Энергетика комплексы** | |
| Электр энергиясе җитештерү, тапшыру һәм бүлү | D. Электр энергиясе, газ һәм пар белән тәэмин итү; һаваны чистарту:<br>35.1.Электр энергиясе җитештерү, тапшыру һәм бүлү |
| Пар һәм кайнар су (җылылык энергиясе) җитештерү, тапшыру һәм бүлү | D. Электр энергиясе, газ һәм пар белән тәэмин итү; һаваны чистарту:<br>35.30.11. Җылылык электр станцияләрендә пар һәм кайнар су (җылылык энергиясе) эшләп чыгару<br>35.30.12. Атом электр станцияләрендә пар һәм кайнар су (җылылык энергиясе) эшләп чыгару<br>35.30.13. Башка электр станцияләре һәм сәнәгать блок-станцияләре тарафыннан пар һәм кайнар су (җылылык энергиясе) эшләп чыгару<br>35.30.15. Суыту максатларыннан суытылган су яки боз (судан ясалган чын) эшләп чыгару |
| Машина төзелеше һәм башка эшкәртү производстволары комплексы (Машина төзелеше комплексы, МК) | |
| Машина төзелеше | |
| Машиналар һәм җиһазлар җитештерү | С. Эшкәртү производстволары:<br>26.4. Көнкүреш электроникасы производствосы |

| Икътисад структурасы: база икътисадый комплекслар – икътисадый комплекслар – тармаклар | ОКВЭД 2 тиешле бүлекләре |
|---|---|
| | 26.5. Контроль-үлчәү һәм навигация приборлары һәм аппаратлары җитештерү; сәгать җитештерү<br>26.6. Медицина максатларында кулланыла торган нурланыш һәм электр терапиясе җиһазлары җитештерү<br>26.7. Оптик приборлар, фото- и кино җиһазлары җитештерү<br>26.8. Яздырылмаган магнитлы һәм оптик техник мәгълүмат саклагычлар җитештерү<br>28.1. Машиналар һәм гомуми билгеләнештәге җиһазлар җитештерү<br>28.2. Гомуми билгеләнештәге башка машиналар һәм җиһазлар җитештерү<br>28.4. Металлар һәм башка каты материаллар эшкәртү өчен станоклар, машиналар һәм җиһазлар җитештерү<br>28.9. Махсус билгеләнештәге башка машиналар җитештерү<br>32.5. Медицина кораллары һәм җиһазлары җитештерү |
| Электр җайланмалары җитештерү | С. Эшкәртү производстволары:<br>27. Электр җайланмалары җитештерү |
| Транспорт чаралары һәм җиһазлар җитештерү | С. Эшкәртү производстволары:<br>28.3. Авыл хуҗалыгы һәм урман хуҗалыгы өчен машиналар һәм җиһазлар җитештерү |
| Автомобильләр җитештерү | С. Эшкәртү производстволары:<br>29. Автотранспортных чаралары, прицеплар һәм ярымприцеплар җитештерү |
| Суднолар төзү һәм ремонтлау | С. Эшкәртү производстволары:<br>30.1. Корабльләр, суднолар һәм көймәләр төзү |
| Очу аппаратлары җитештерү | С. Эшкәртү производстволары:<br>30.3. Очу аппаратлары, космик һәм тиешле җиһазларны да кертеп, җитештерү |
| Башка транспорт чаралары | С. Эшкәртү производстволары:<br>30.2. Тимер юл локомотивлары һәм хәрәкәт составын җитештерү<br>30.9. Башка төркемнәргә кертелмәгән транспорт чаралары һәм җиһазлар җитештерү<br>30.4. Хәрби сугыш машиналары җитештерү |
| Металлургия производствосы | С. Эшкәртү производстволары:<br>24. Металлургия производствосы (24.46 «Атом ягулыгы җитештерү»дән тыш)<br>25. Машиналар һәм җиһазлардан тыш, әзер металл эшләнмәләр җитештерү |

| Икътисад структурасы: база икътисадый комплекслар – икътисадый комплекслар – тармаклар | ОКВЭД 2 тиешле бүлекләре |
|---|---|
| **Җиңел сәнәгать, агач эшкәртү сәнәгате һәм башка эшкәртү производстволары** | |
| Текстиль һәм тегү производствосы | С. Эшкәртү производстволары:<br>13. Текстиль эшләнмәләр җитештерү<br>14. Кием җитештерү |
| Тире һәм күн әйберләр җитештерү | С. Эшкәртү производстволары:<br>15. Тире һәм күн әйберләр җитештерү |
| Агач эшкәртү һәм агачтан әйберләр җитештерү | С. Эшкәртү производстволары:<br>16. Агач эшкәртү, агачтан һәм пробкадан әйберләр җитештерү, мебельдән кала, салам һәм үрү материалларыннан әйберләр җитештерүдән тыш |
| Целлюлоза-кәгазь җитештерү | С. Эшкәртү производстволары:<br>17. Кәгазь һәм кәгазь әйберләр җитештерү |
| Башкалар | С. Эшкәртү производстволары:<br>31. Мебель җитештерү<br>32. Башка әзер эшләнмәләр җитештерү (32.5 «Медицина кораллары һәм җиһазлары җитештерү»дән тыш)<br>32.9. Башка төркемнәргә кертелмәгән әйберләр җитештерү |
| **Агросәнәгать комплексы (АПК)** | |
| **Авыл хуҗалыгы** | |
| Үсемлекчелек | А. Авыл хуҗалыгы, урман хуҗалыгы, аучылык, балыкчылык һәм балык үрчетү:<br>01.1. Берьеллык культуралар үстерү<br>01.2. Күпьеллык культуралар үстерү<br>01.3. Үсентеләр үстерү<br>01.5. Катнаш авыл хуҗалыгы<br>01.61. Үсемлекчелек өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү<br>01.63. Уңышны җыеп алганнан соң авыл хуҗалыгы эшчәнлеге<br>01.64. Утырту өчен орлык эшкәртү |
| Терлекчелек | А. Авыл, урман хуҗалыгы, аучылык, балыкчылык һәм балык үрчетү:<br>01.4. Терлекчелек<br>01.62. Терлекчелек өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү |
| **Азык-төлек продуктлары җитештерү** | |
| Ит һәм ит продуктлары җитештерү | С. Эшкәртү производстволары:<br>10.1.Ит һәм ашарга яраклы ит продукциясен эшкәртү |

| Икътисад структурасы: база икътисадый комплекслар – икътисадый комплекслар – тармаклар | ОКВЭД 2 тиешле бүлекләре |
|---|---|
| | һәм консервалау |
| Үсемлек һәм терлек майлары җитештерү | С. Эшкәртү производстволары:<br>10.4.Үсемлек һәм терлек майлары җитештерү |
| Сөт продуктлары җитештерү | С. Эшкәртү производстволары:<br>10.5.Сөт продукциясе җитештерү |
| Он тарту – ярма сәнәгате продуктлары, крахмаллар һәм крахмал продуктлары җитештерү | С. Эшкәртү производстволары:<br>10.6. Он тарту – ярма сәнәгате продуктлары, крахмал һәм крахмаллы продуктлар җитештерү |
| Хайваннар өчен әзер азык җитештерү | С. Эшкәртү производстволары:<br>10.9.Хайваннар өчен әзер азык җитештерү |
| Эчемлекләр җитештерү | С. Эшкәртү производстволары:<br>11. Эчемлекләр җитештерү |
| Башка азык-төлек продуктлары җитештерү | С. Эшкәртү производстволары:<br>10.2.Балыкны, кысласыманнарны һәм моллюскларны эшкәртү һәм консервалау<br>10.3. Җиләк-җимешләрне һәм яшелчәләрне эшкәртү һәм консервалау<br>10.7. Ипи-күмәч һәм камыр кондитер ризыклары җитештерү<br>10.8. Ашарга яраклы башка продуктлар җитештерү |
| **Балыкчылык, балык үрчетү** | А. Авыл, урман хуҗалыгы, аучылык, балыкчылык һәм балык үрчетү:<br>01.7. Аучылык, кыргый җәнлекләрне тоту һәм ату, бу өлкәләрдә хезмәтләр күрсәтүне дә кертеп<br>03. Балыкчылык һәм балык үрчетү |
| **Урман хуҗалыгы** | А. Авыл хуҗалыгы, урман хуҗалыгы, аучылык, балыкчылык һәм балык үрчетү:<br>02. Урман үстерү һәм агач материаллары хәзерләү |
| **Инфраструктура комплексы (ИК)** | |
| **Сәүдә комплексы** | G. Күпләп һәм ваклап сату; автотранспорт чараларын һәм мотоциклларны ремонтлау:<br>45. Автотранспорт чараларын һәм мотоциклларны күпләп һәм ваклап сату һәм аларны ремонтлау<br>46. Күпләп сату, автотранспорт чараларын һәм мотоциклларны күпләп сатудан тыш<br>47. Ваклап сату, автотранспорт чараларын һәм мотоциклларны сатудан тыш |
| **Төзелеш комплексы һәм ТКХ** | |
| **Торак-коммуналь хуҗалык комплексы** | |
| Су җыю, чистарту һәм бүлү | D. Электр энергиясе, газ һәм пар белән тәэмин итү; |

| Икътисад структурасы: база икътисадый комплекслар – икътисадый комплекслар – тармаклар | ОКВЭД 2 тиешле бүлекләре |
|---|---|
| | һаваны кондиционирлау:<br>35.30.14. Котельняларда пар һәм кайнар су (җылылык энергиясе) эшләп чыгару<br>35.30.2. Пар һәм кайнар суны (җылылык энергиясен) тапшыру<br>35.30.3. Пар һәм кайнар суны (җылылык энергиясен) бүлү<br>35.30.4. Котельняларның эшләвен тәэмин итү<br>35.30.5. Җылылык челтәрләренең эшләвен тәэмин итү<br>35.30.6. Парны һәм кайнар суны (җылылык энергиясен) сату<br>Е. Су белән тәэмин итү; ташландык суны чыгару, калдыкларны җыюны һәм утильләштерүне оештыру, пычрану очракларын бетерү буенча эшчәнлек:<br>36. Су чыгару, чистарту һәм бүлү |
| Агым суларны, калдыкларны җыю һәм охшаш эшчәнлек | Е. Су белән тәэмин итү; ташландык суны чыгару, калдыкларны җыюны һәм утильләштерүне оештыру, пычрану очракларын бетерү буенча эшчәнлек:<br>37. Агым суларны җыю һәм чистарту<br>38. Калдыкларны җыю, эшкәртү һәм утильләштерү; икенчел чималны эшкәртү<br>39. Пычратудан килгән зыянны бетерү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү һәм калдыкларны алу белән бәйле башка хезмәтләр күрсәтү |
| Күчемсез мөлкәт белән операцияләр | L. Күчемсез мөлкәт белән операцияләр буенча эшчәнлек |
| **Төзелеш комплексы** | |
| Төзелеш | F. Төзелеш:<br>41. Биналар төзү<br>42. Инженерлык корылмалары төзү<br>43. Махсуслаштырылган төзелеш эшләре |
| Металл булмаган башка минерал продуктлар җитештерү | С. Эшкәртү производствосы:<br>23. Металл булмаган башка минерал продукцияләр җитештерү |
| Башка файдалы казылмалар табу | В. Файдалы казылмалар табу:<br>08. Башка файдалы казылмалар табу (08.92 «Торф чыгару һәм аның агломерациясе»ннән тыш)<br>09.9. Файдалы казылмалар чыгаруның башка өлкәләрендә хезмәтләр күрсәтү |
| **Транспорт-логистика комплексы** | |
| Тимер юл транспорты | Н. Транспортировкалау һәм саклау:<br>49.1. Тимер юл транспорты эшчәнлеге: шәһәрара һәм |

| Икътисад структурасы: база икътисадый комплекслар – икътисадый комплекслар – тармаклар | ОКВЭД 2 тиешле бүлекләре |
|---|---|
| | халыкара пассажирлар ташу<br>49.2. Тимер юл транспорты эшчәнлеге: йөк ташу<br>49.3. Коры җирдән йөри торган башка пассажир транспорты эшчәнлеге |
| Автомобиль транспорты | Н. Транспортировкалау һәм саклау:<br>49.4. Автомобиль йөк транспорты эшчәнлеге һәм йөк ташу буенча хезмәтләр күрсәтү |
| Су транспорты | Н. Транспортировкалау һәм саклау:<br>50. Су транспорты эшчәнлеге |
| Һава транспорты | Н. Транспортировкалау һәм саклау:<br>51. Һава һәм космос транспорты эшчәнлеге |
| Ярдәмче һәм өстәмә транспорт эшчәнлеге | Н. Транспортировкалау һәм саклау:<br>52. Склад хуҗалыгы һәм ярдәмче транспорт эшчәнлеге |
| **Телекоммуникация комплексы** | Н. Транспортировкалау һәм саклау:<br>53. Почта элемтәсе эшчәнлеге һәм курьерлык эшчәнлеге<br>J. Мәгълүмат һәм элемтә өлкәсендә эшчәнлек:<br>60. Телевидение һәм радиотапшырулар өлкәсендә эшчәнлек<br>61. Телекоммуникацияләр өлкәсендә эшчәнлек |
| **Хезмәтләр күрсәтү комплексы (ХКК)** | |
| **Фән-мәгариф комплексы** | |
| Мәгариф | Р. Мәгариф |
| Фәнни тикшеренүләр һәм уйлап табулар | М. Һөнәри, фәнни һәм техник эшчәнлек:<br>72. Фәнни тикшеренүләр һәм уйлап табулар |
| **Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү комплексы** | Q. Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшчәнлек:<br>86. Сәламәтлек саклау өлкәсендә эшчәнлек<br>87. Яшәү урыны белән тәэмин итү белән бергә авыруларны карау эшчәнлеге<br>88. Яшәү урыны белән тәэмин итмичә социаль хезмәтләр күрсәтү |
| **Туристиклык-рекреация комплексы** | |
| Кунакханәләр һәм рестораннар | I. Кунакханәләр һәм җәмәгать туклануы предприятиеләре эшчәнлеге:<br>55. Вакытлыча яшәп тору өчен урыннар бирү буенча эшчәнлек<br>56. Туклану продуктларын һәм эчемлекләр бирү буенча эшчәнлек |
| Туристлык агентлыклары эшчәнлеге | N. Административ эшчәнлек һәм шуңа бәйле өстәмә |

| Икътисад структурасы: база икътисадый комплекслар – икътисадый комплекслар – тармаклар | ОКВЭД 2 тиешле бүлекләре |
|---|---|
| | хезмәтләр күрсәтү:<br>79. Туристлык агентлыклары һәм туризм өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче башка оешмалар эшчәнлеге |
| Ял итүне һәм күңел ачуларны, мәдәниятне һәм спортны оештыру буенча эшчәнлек | J. Мәгълүмат һәм элемтә өлкәсендә эшчәнлек<br>59. Кинофильмнар, видеофильмнар һәм телевизион программалар эшләү, тавыш язмаларын һәм ноталар чыгару<br>R. Мәдәнията, спорт, буш вакытны һәм күңел ачуларны оештыру өлкәсендә эшчәнлек:<br>90. Иҗади эшчәнлек, сәнгать һәм күңел ачуларны оештыру өлкәсендә эшчәнлек<br>91. Китапханәләр, архивлар, музейлар һәм башка мәдәният объектлары эшчәнлеге<br>92. Комарлы уеннарны оештыру һәм уздыру, парилар төзү, лотереялар оештыру һәм уздыру буенча эшчәнлек<br>93. Спорт, ял һәм күңел ачулар өлкәсендә эшчәнлек |
| **Мәгълүмат-технология комплексы** | C. Эшкәртү производстволары:<br>26.1. Электрон аппаратура һәм басма схемалар (платалар) өлешләрен җитештерү<br>26.2. Компьютерлар һәм периферия җиһазлары җитештерү<br>26.3. Коммуникация җиһазлары җитештерү<br>J. Мәгълүмат һәм элемтә өлкәсендә эшчәнлек:<br>62. Компьютерның программалар белән тәэмин ителешен уйлап табу, әлеге өлкәдә консультация хезмәтләре күрсәтү һәм шуңа бәйле башка хезмәтләр күрсәтү<br>63. Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә эшчәнлек |
| **Дәүләт хезмәтләре һәм хосусый хезмәтләр күрсәтү комплексы** | |
| Финанс комплексы | K. Финанс һәм иминләштерү эшчәнлеге:<br>64. Финанс хезмәтләре күрсәтү буенча эшчәнлек, иминләштерү һәм пенсия белән тәэмин итү буенча хезмәтләр күрсәтүдән тыш<br>65. Иминләштерү, яңадан иминләштерү, дәүләтнеке булмаган пенсия фондлары эшчәнлеге, мәҗбүри социаль тәэмин итүдән тыш<br>66. Финанс хезмәтләре күрсәтү һәм иминләштерү өлкәсендә ярәмче эшчәнлек |
| Дәүләт идарәсе, хәрби иминлекне, мәҗбүри социаль тәэминатны тәэмин итү комплексы | O. Дәүләт идарәсе һәм хәрби иминлекне тәэмин итү; социаль тәэминат |
| Эшлекле һәм шәхси хезмәтләр күрсәтү комплексы | S. Башка төр хезмәтләр күрсәтү: |

| Икътисад структурасы: база икътисадый комплекслар – икътисадый комплекслар – тармаклар | ОКВЭД 2 тиешле бүлекләре |
|---|---|
| | 94. Иҗтимагый оешмалар эшчәнлеге<br>95. Компьютерлар, шәхси кулланылыш һәм хуҗалык-көнкүреш билгеләнешендәге әйберләр ремонтлау<br>96. Башка төр шәхси хезмәтләр күрсәтү буенча эшчәнлек<br>N. Административ эшчәнлек һәм шуңа бәйле өстәмә хезмәтләр күрсәтү:<br>77. Аренда һәм лизинг<br>78. Эшкә урнаштыру һәм персонал сайлап алу буенча эшчәнлек<br>80. Иминлекне тәэмин итү һәм тикшерүләр үткәрү буенча эшчәнлек<br>81. Биналарга һәм территорияләргә хезмәт күрсәтү буенча эшчәнлек<br>82. Административ-хуҗалык эшчәнлеге, оешманың эшләвен тәэмин итү буенча ярдәмче эшчәнлек, бизнес өчен башка ярдәмче хезмәтләр күрсәтү буенча эшчәнлек<br>M. Һөнәри, фәнни һәм техник эшчәнлек:<br>69. Хокук һәм бухгалтерлык исәп-хисабы өлкәсендә эшчәнлек<br>70. Баш офислар эшчәнлеге; идарә мәсьәләләре буенча консультацияләр бирү<br>71. Архитектура һәм инженерлык-техник проектлау өлкәсендә эшчәнлек; техник сынаулар, тикшеренүләр һәм анализ<br>73. Реклама эшчәнлеге һәм базар конъюнктурасын өйрәнү<br>74. Һөнәри фәнни һәм башка техник эшчәнлек<br>75. Ветеринария эшчәнлеге<br>C. Эшкәртү производстволары:<br>18. Полиграфия эшчәнлеге һәм мәгълүмат чыганакларыннан күчермәләр алу<br>33. Машиналарны һәм җайланмаларны ремонтлау һәм монтажлау<br>J. Мәгълүмат һәм элемтә өлкәсендә эшчәнлек:<br>58. Нәширлек эшчәнлеге<br>T. Эш бирүчеләр буларак йорт хуҗалыклары эшчәнлеге; шәхси кулланылыш өчен товарлар җитештерү һәм хезмәтләр күрсәтү буенча хосусый йорт хуҗалыкларының дифференциацияләнмәгән эшчәнлеге |

Искәрмә. Икътисадый комплекслар структурасын төзегәндә ОКВЭД 2 каралган һәм Татарстан Республикасы икътисадында булмаган түбәндәге эшчәнлек төрләре күрсәтелмәде:

В бүлеге:

- 05. Ташкүмер чыгару;
- 07. Металл рудалары чыгару;
- 08.92. Торф чыгару һәм аның агломерациясе;

С бүлеге:

- 12. Тәмәке эшләнмәләре җитештерү;
- 19.1. Кокс җитештерү;
- 19.3. Ташкүмер, антрацит һәм көрән ташкүмер (лигнит) агломерациясе һәм термоташкүмер җитештерү;
- 24.46. Атом-төш ягулыгы җитештерү;

U бүлеге.»;

б) 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясенә 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2030 елга кадәр Татарстан Республикасын
социаль-икътисадый үстерү стратегиясенә
2 нче кушымта

**2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль -икътисадый үстерү стратегиясенең максатлары һәм бурычлары системасы**

**Төп стратегик максат (ГСЦ)**

<u>**ГСЦ**</u> **Татарстан-2030 – глобаль конкурентлыкка сәләтле тотрыклы регион, «Идел-Кама» үсеш полюсы драйверы. Татарстан – кеше капиталының, институтларның, инфраструктураның, икътисадның, тышкы интеграциянең (Россиянең үзәк Евразия регионы) һәм эчке пространствоның үзара бәйлелегенең сыйфаты буенча алдынгы; алда бара торган темплар белән үсә торган, халыкара эш бүленешенә югары дәрәҗәдә кушылган регион.**

**Стратегик максатлар (СЦ)**

<u>**СЦ-1**</u> **Кеше капиталы.**Тупланган кеше капиталы Татарстан Республикасының конкурентлык сәләтен тәэмин итә. Республика яшәүнең югары сыйфатына ирешү өчен шартлар тудыру аша төп актив буларак кеше капиталын туплауда алдынгы булып тора.

<u>**СЦ-2**</u> **Пространство, реаль капитал.** Территорияләрнең һәм пространствоның тигез үсүе мохитнең югары конкурентлык сәләтен тәэмин итә; инфраструктура глобаль конкурентлык сәләтенә ия. Җитештерү фондлары нәтиҗәле кулланыла.

<u>**СЦ-3**</u> **Базарлар.** Татарстан Республикасының махсуслаштыру тармаклары регионара һәм глобаль базарларда конкурентлыкка сәләтле.

**<u>СЦ-4</u>** **Институтлар.** Дәүләт, хосусый һәм дәүләт-хосусый институтларның балanслы системасы конкурентлыкка сәләтле кластерларның, эшкуарлыкның (кече һәм урта бизнесның), эчке территориаль үсешнең һәм тышкы интеграциянең тотрыклы үсешен тәэмин итә.

**<u>СЦ-5</u>** **Инновацияләр һәм мәгълүмат.** Республика «акыллы» икътисад үстерүдә, яңа материаллар, продуктлар һәм технологияләр булдыруда һәм аларны коммерцияләштерүдә алдынгы булып тора.

**<u>СЦ-6</u>** **Табигать ресурслары.** Табигать ресурслары тотрыклы үсеш принциплары нигезендә нәтиҗәле кулланыла.

**<u>СЦ-7</u>** **Финанс капиталы.** Республика дөньякүләм дәрәҗәдәге инвестицияләр өчен кызыклы булып тора. Финанс системасы югары нәтиҗәле.

**Юнәлешләр буенча максатлар (Ц) һәм бурычлар (З)**

**Кеше капиталы**

**<u>СЦ-1</u>** **Тупланган кеше капиталы Татарстан Республикасының конкурентлык сәләтен тәэмин итә. Республика яшәүнең югары сыйфатына ирешү өчен шартлар тудыру аша төп актив буларак кеше капиталын туплауда алдынгы булып тора.**

**Ц-1.1** **Татарстан – туучылар саны югары һәм халыкның миграция агымы тотрыклы булган үсә торган регион.**

*З-1.1.0.1* Туучылар санының суммар коэффициенты үсешен тәэмин итәргә.

*З-1.1.0.2* Хатын-кызларга ата-ана бурычларын эш белән тәэмин ителүе белән бергә алып бару өчен шартлар тудырырга.

*З-1.1.0.3* Хезмәткә сәләтле яшьтә үлүчеләр санын һәм идарә ителә торган сәбәпләрдән үлемнәрне киметү исәбенә көтелгән гомер озынлыгын озайтуны тәэмин итәргә.

*З-1.1.0.4* Регионның социаль-икътисадый үсешенә халыкның картаюы йогынтысының тискәре нәтиҗәләрен киметергә.

*З-1.1.0.5* Халыкның һәм хезмәт мигрантларының агымын җайга салу өчен шартлар булдырырга.

*З-1.1.0.6* Республикадан яшь буынның, квалификацияле белгечләрнең читкә китүен киметү өчен шартлар тудырырга.

*З-1.1.0.7* Республикада мигрантларның адаптацияләнүенә һәм интеграцияләнүенә ярдәм итү чаралары комплексын гамәлгә ашырырга.

*З-1.1.0.8* Көтелгән сәламәт яшәү дәвамлылыгын 67 яшькә кадәр арттыруны тәэмин итәргә.

*З-1.1.0.9* Сәламәт яшәү рәвеше алып бара торган гражданнар саны артуны тәэмин итәргә.

**Ц-1.2** **Мәгариф системасы Татарстан җәмгыятенең һәм икътисадының ихтыяҗларына туры килә торган кеше капиталын булдыруны тәэмин итә.**

**Ц-1.2.1** **Гаиләләр балаларны һәрьяклап үстерүдә һәм аларны мәктәптә укуга әзерләүдә нәтиҗәле ярдәм белән тәэмин ителде.**

*З-1.2.1.1* Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү торышын

һәрьяклап тикшерергә.

*З-1.2.1.2* Уңайлы файдалану мөмкинлекләрен исәпкә алып, инфраструктураны яңартырга, заманча мультимедия технологияләрен гамәлгә кертергә.

*З-1.2.1.3* Мәктәпкәчә белем бирү өлкәсендә дәүләтнеке булмаган секторның өлешен арттырырга.

*З-1.2.1.4* Гаиләләрдә һәм яслеләрдә балаларның иртә үсешен тәэмин итеп бару системасын булдырырга.

*З-1.2.1.5* Балаларның үсешен тәэмин итеп баруның ведомствоара координацияләү системасын эшләргә.

*З-1.2.1.6* Авырлыкларны иртә ачыклау һәм аларны хәл итүдә ярдәм итү өчен балаларның үсешен индивидуаль тәэмин итеп бару системасын булдырырга.

**Ц-1.2.2 Гомуми белем бирү, индивидуаль үзенчәлекләрне исәпкә алып, һәр мәктәп баласының социальләшүен һәм белем алуда югары казанышларга ирешүен, мәгълүмати технологияләр өлкәсендә күнекмәләр үсешен тәэмин итә.**

*З-1.2.2.1* Заманча архитектура, идарә итү, технологик һәм педагогик чишелешләрне берләштерә торган мохит булдырырга.

*З-1.2.2.2* Белем бирү ресурсларыннан файдалану тигезлеген тәэмин итә торган механизмнар эшләргә.

*З-1.2.2.3* Сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен инклюзив белем бирүне тәэмин итәргә.

*З-1.2.2.4* Гаиләләрнең, урындагы җәмәгатьчелекнең, бизнесның уку-укыту процессында, белем бирү сыйфатын бәяләүдә һәм мәктәпләр белән идарә итүдә катнашу мөмкинлекләрен киңәйтергә.

*З-1.2.2.5* Укытуның заманча рәвешләрен, профильле укытуны кертеп, үстерү исәбенә, гомуми һәм өстәмә белем бирүне интеграцияләү исәбенә белем алучыларның белем алу индивидуальлегенең һәм академик мобильлегенең югары дәрәҗәсен тәэмин итәргә.

*З-1.2.2.6* Белем бирү сыйфатын бәяләүнең республика системасын булдырырга.

*З-1.2.2.7* Россия Федерациясендә алдынгылыкка ирешү өчен мәгълүмат технологияләре һәм математика өлкәсендә белем бирүне үстерүгә өстенлек бирергә.

*З-1.2.2.8* Сәләтле балаларны һәм яшьләрне барларга һәм аларга ярдәм итәргә.

*З-1.2.2.9* Педагогик белем бирү системасын яңартырга.

*З-1.2.2.10* Иң яхшы яшь педагогик кадрлар килүен һәм аларның һөнәри үсешен тәэмин итәргә.

*З-1.2.2.11* Мәктәпләрне үз-үзләрен укытучы оешмалар буларак үстерү стратегияләрен гамәлгә ашыручы алдынгы директорлар корпусын оештырырга.

*З-1.2.2.12* Балалар-яшүсмерләр оешмаларының республика системасын һәм хәйрия, гражданлык-патриотик, ихтыярый ярдәм (волонтерлык), экологик һәм башка юнәлештәге хәрәкәтләрне үстерүне оештыру ягыннан һәм методик яктан алып баруны тәэмин итәргә.

*З-1.2.2.13* Дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

*З-1.2.2.14* Педагогика хезмәткәрләрен һөнәри яктан үстерүнең милли системасын кертү.

**Ц-1.2.3** **Һөнәри белем масштаблары һәм сыйфаты инновацион икътисад таләпләренә һәм халыкның социаль ихтыяҗларына туры килә, һөнәри белем бирү оешмалары белән нәтиҗәле системалы идарә итү җайга салынган.**

*З-1.2.3.1* Уку-укыту программаларының яраклашучанлыгын арттырырга, халыкның төрле категорияләренә гомер буена һөнәри белем алу мөмкинлеген тудырырга.

*З-1.2.3.2* Һөнәри белем бирү оешмалары челтәрен оптимальләштерергә.

*З-1.2.3.3* Эш бирүчеләр белән, шул исәптән инновацион предприятиеләр белән нәтиҗәле партнерлык булдырырга.

*З-1.2.3.4* Һөнәри өйрәтү программаларын иҗтимагый-һөнәри аккредитацияләү һәм һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларны сертификацияләү системасын оештырырга.

*З-1.2.3.5* Урта һөнәри белем бирү системасына ребрендинг үткәрергә.

*З-1.2.3.6* Урта һөнәри белем бирү системасы өчен кадрлар әзерләргә.

*З-1.2.3.7* Рәсми булмаган белем бирүне үстерүгә һәм яшьләрне үзлегеннән белем алу белән кызыксынуын арттыруга юнәлтелгән инновацияле белем бирү технологияләрен кертергә.

*З-1.2.2.8* Урта һөнәри белем бирү өлкәсендә тәрбия бирү эше системасын төзергә һәм үстерергә.

**Ц-1.2.4** **Татарстан – югары белемнең һәм фәннең конкурентлыкка сәләтле үзәге, талантлар җәлеп итүче лидер регион.**

*З-1.2.4.1* Әйдәп баручы тикшеренү һәм инновация университетларында җитди конкурентлыкка сәләтле булган белем бирүгә ирешергә.

*З-1.2.4.2* Массакүләм югары белемнең канәгатьләнерлек сыйфатын тәэмин итәргә.

*З-1.2.4.3* Россия Федерациясенең әйдәп баручы югары уку йортлары һәм чит ил университетлары белән партнерлыкны үстерергә.

*З-1.2.4.4* Татарстан икътисадының инновацион секторы белән партнерлыкны үстерергә.

*З-1.2.4.5* Юнәлешләр буенча югары уку йортлары төркемнәрен булдырырга: югары белем бирүнең федераль һәм халыкара базарларында конкурентлыкка сәләтле җитди федераль югары уку йортлары; регионның һәм макрорегионның икътисадый ихтыяҗларын тәэмин итү өчен эшли торган көчле бакалавриаты булган (шул исәптән урта һөнәри белем бирү белән берлектә) югары уку йортлары; халыкның сыйфатлы социаль-икътисадый һәм гуманитар белгечлекләргә ихтыяҗын тәэмин итә торган киң юнәлештәге югары уку йортлары (шул исәптән «аерымланган» территорияләрдә).

*З-1.2.4.6* Югары уку йортлары базасында өзлексез белем бирү системасын оештыру аркылы филиаллар челтәре сыйфатын яхшыртырга (шул

исәптән хезмәт эшчәнлегенә актив кушылган халык өчен).

*3-1.2.4.7* Регионның һәм макрорегионның эш бирүчеләре, аеруча инновация компанияләре белән югары белем бирү системасын координацияләү һәм аның белән үзара хезмәттәшлек итү механизмнарын үстерергә.

*3-1.2.4.8* Югары уку йортларында идеяләрне һәм эшләнмәләрне коммерцияләштерү системасын җайга салырга.

*3-1.2.4.9* Россиянең һәм чит илләрнең әйдәп баручы галимнәренә һәм яшь перспективалы тикшеренүчеләренә Татарстан Республикасында эшләүнең җәлеп итүчәнлеген тәэмин итәргә.

*3-1.2.4.10* Рәсми булмаган белем бирүне үстерүгә һәм яшьләрне үзлегеннән белем алу белән кызыксынуын арттыруга юнәлтелгән инновацияле белем бирү технологияләрен кертергә.

*3-1.2.4.11* Югары уку йортларында тәрбия бирү эше системасын камилләштерергә.

**Ц-1.3 Татарстан Республикасы халкының һәм сәламәтлек саклау системасының мөһим бурычлары – сәламәтлекне саклау һәм озак яшәү.**

*3-1.3.0.1* Персоналның мотивациясен арттырырга һәм тармакның кадрлар потенциалын ныгытырга.

*3-1.3.0.2* Аерым авырулардан (кан әйләнеше системасы авыруларыннан, юл-транспорт һәлакәтләре җәрәхәтләреннән, шеш авыруларыннан, туберкулездан һ.б.) вафат булу, хезмәткә сәләтле яшьтәгеләрнең вафат булу, балаларның вафат булу очраклары санын киметергә.

*3-1.3.0.3* Халыкта авыруларның көчәюен киметүгә һәм сәламәтлекне саклап калуга юнәлдерелгән тәртип модельләрен формалаштырырга.

*3-1.3.0.4* Сәламәтлек саклау системасын модернизацияләргә, бу аның нәтиҗәлелеген арттырачак.

*3-1.3.0.5* Эш бирүчеләрнең үз хезмәткәрләренең сәламәтлеген саклауга, һөнәри һәм һөнәргә бәйле авыруларның барлыкка килүен кисәтүгә юнәлдерелгән хезмәт шартларын тудыруга мотивациясен арттырырга.

*3-1.3.0.6* Сәламәтлек саклау өлкәсенең ресурс базасын киңәйтергә, медицинада икътисадның үсеш нокталарын булдырырга.

*3-1.3.0.7* Татарстан сәламәтлек саклау системасының җитди конкурентлык сәләтен арттырырга, республика халкының һәм башка регионнарда яшәүчеләрнең инновацион технологияләрдән файдалана алуын тәэмин итәргә, тармакның кадрлар потенциалын саклап калырга һәм арттырырга, Татарстан Республикасы икътисадына инвестицияләр җәлеп итәргә.

*3-1.3.0.8* Ярдәм күрсәтүнең перспектив һәм заманча модельләрен кертү исәбенә гамәлдәге сәламәтлек саклау системасының нәтиҗәлелеген күтәрергә.

*3-1.3.0.9* Медицина иминияте һәм социаль иминият системаларын бүлү, иминләштерелгән затларның үз сәламәтлекләрен саклау буенча шәхси җаваплылыгын арттыру шартларында бәла-каза хәвефләреннән озак сроклы тупланма иминиятне кертү исәбенә халыкның медицина ярдәменә дифференциацияләнгән ихтыяҗларын канәгатьләндерергә.

*З-1.3.0.10* Барлык гражданнарны да ике елга кимендә бер тапкыр профилактик медицина тикшеренүе белән колачлауны тәэмин итәргә.

*З-1.3.0.11* Беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтә торган медицина оешмаларының халык өчен (шул исәптән ерактагы җирлекләрдә урнашкан торак пунктларда яшәүчеләр өчен дә) оптималь уңайлылыгын тәэмин итәргә, гражданнарның әлеге медицина оешмаларына ярдәм сорап мөрәҗәгать итүләре очрагында чиратта тору вакытын кыскартырга, табибка язылу процедурасын гадиләштерергә.

*З-1.3.0.12* Медицина хезмәтләре күрсәтү экспорты күләмен арттыруны тәэмин итәргә.

*З-1.3.0.13* Балалар һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру системасын камилләштерергә.

**Ц-1.4** **Мәдәни тормышның сыйфаты һәм төрлелеге кеше капиталын җәлеп итүнең һәм туплауның чын факторлары булып тора.**

*З-1.4.0.1* Мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә Татарстан Республикасының югары казанышларына булышырга.

*З-1.4.0.2* Мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә мәгариф системасын яхшырту, гомуми һәм өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары һәм мәдәният учреждениеләре кооперациясе һәм интеграциясе исәбенә иҗади кадрларны арттырып әзерләүне тәэмин итәргә.

*З-1.4.0.3* Мәдәни мирасны күчмә мәдәни туризм факторы буларак саклап калырга һәм актуальләштерергә.

*З-1.4.0.4* Иҗади индустрияләрнең интенсив үсеше һәм экспорт өчен эчке базарны һәм мөмкинлекләрне арттыру исәбенә аларның конкурентлык сәләтен арттыру өчен шартлар тудырырга.

*З-1.4.0.5* Шәһәр агломерацияләрендә мәдәният инфраструктурасын алдан үстерүне тәэмин итәргә.

*З-1.4.0.6* Күчмә мәдәният-мәгълүмат комплексларын һәм гастроль эшчәнлеген тарату аша авылда һәм ерак территорияләрдә яшәүчеләрнең мәдәниятнең югары казанышларыннан файдалана алуын һәм мәдәният тормышында катнашуын тәэмин итәргә.

*З-1.4.0.7* Аралашуның һәм үз-үзеңне тотуның гомуми культурасын арттырырга.

**Ц-1.5** **Үзгәрүчән хезмәт базары, хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру, эш белән тәэмин итүгә булышу һәм социаль яклау системасы эш белән тәэмин итүнең нәтиҗәле булуын һәм кеше капиталына куйган көчтән кокурент керемнәр алуны тәэмин итә.**

*З-1.5.0.1* Инновацион икътисад өчен Татарстан Республикасына кадрлар җәлеп итәргә һәм аларны саклап калырга.

*З-1.5.0.2* Үзгәрүчәнлекне, якланганлыкны һәм идарә ителүчәнлекне тәэмин итә торган хезмәт базары моделен кертергә.

*З-1.5.0.3* Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышуның актив чаралары өчен төгәл максатлар билгеләп, эш белән тәэмин итү хезмәтләренең

файдасын һәм нәтиҗәлелеген күтәрергә.

*3-1.5.0.4* Эшче көчләрне нәтиҗәлерәк файдалану өчен республика чикләрендә халыкның территориаль мобильлеген һәм хезмәт миграциясен җиңеләйтергә.

*3-1.5.0.5* Хезмәт базарына республиканың икътисадый актив булмаган халкын, аеруча балалы хатын-кызларны, башка регионнардан хезмәт мигрантларын җәлеп итәргә, пенсия яшендәге халыкның хезмәт активлыгын саклауны стимуллаштырырга.

*3-1.5.0.6* Мохтаҗлыкны бәяләү һәм социаль килешү принциплары нигезендә гамәлгә ашырыла торган программалар ярдәмендә балалары булган ярлы гаиләләрнең социаль якланганлык дәрәҗәсен арттырырга.

*3-1.5.0.7* Өлкән яшьтәге кешеләргә социаль ярдәм күрсәтү сыйфатын һәм мөмкинлеген арттырырга, шулай ук аларны, актив озын гомерле булуына ирешү максатыннан, компьютер грамотасына өйрәтергә.

*3-1.5.0.8* Икътисадның чималга карамаган төп тармакларының урта һәм эре предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлегенең елына кимендә 5 процентка артуын тәэмин итәргә.

**Пространство, реаль капитал**

**<u>СЦ-2</u>** **Территорияләрнең һәм пространствоның тигез үсүе мохитнең югары конкурентлыгын тәэмин итә; инфраструктура глобаль конкурентлыкка сәләтле була. Җитештерү фондлары нәтиҗәле файдаланыла.**

**Ц-2.1** **Пространство кеше ресурсларын саклап калу һәм җәлеп итү өчен, гомернең төрле яшь этапларында һәм төрле тормыш рәвешләре контекстында шәхеснең тулы кыйммәтле үсеше өчен шартлар тудыра.**

**Ц-2.2** **Пространство үсеше Татарстан Республикасының социаль-икътисадый факторларына һәм географик шартларына – Евразия үзәгендә урнашуга – нигезләнеп бара.**

**Ц-2.3** **Пространствода тоткан урыны дөньяви җәмгыятьтә Татарстан Республикасы статусын күтәрүгә, хезмәт һәм технологияләр бүленешенең дөньякүләм системасында уникаль урынын табуга булыша.**

**Ц-2.4** **Пространство алдынгы стандартларга туры килә һәм яңа технологик торышларны танытуга булыша (3.7 нче рәсем).**

**Ц-2.5** **Республика территориясендә бердәм социомәдәни пространство саклана.**

**Ц-2.6** **Интеллектуаль һәм экологик чиста технологияләр һәм хәл итүләр нигезендә үсә торган өч агломерацияне: (Казан, Кама һәм Әлмәт агломерацияләрен) берләштерә торган челтәр тибындагы өчүзәкле ИделКама метрополисы формалашты.**

**Ц-2.7** **Пассажирлар хәрәкәте өчен таләп ителә торган мөмкинлекләрне тәэмин итүче транспорт-коммуникация системасы сыйфатының югары күрсәткечләренә ирешелде.**

**Ц-2.8** **Татарстан Республикасында барлык эчке, агломерацияләр**

**арасындагы, регионнар арасындагы транспорт юнәлешләренең, шулай ук халыкара транспорт коридорларының югары синергиясе: «Идел-Кама» үсеше полюсының тотрыклы тиз йөрешле транспорт каркасы формалашты.**

**Ц-2.9** **Сыйфатлы торак киңлеге һәм уңайлы шәһәр мохите үсә.**

*З-2.0.0.1* Фаразлана торган саны 4 182 мең кеше булачак (2013 ел белән чагыштырганда, 350 мең кешегә артык) республика халкының тормыш эшчәнлегенең сыйфатлы пространство белән, дүртенче технологик торышның булган ресурсларыннан файдаланып һәм, 2030 елга кадәр алтынчы торышка күчү перспективасы белән, 2020 елга бишенче торышта эшчәнлеккә актив күчүгә бәйле эшчәнлек өлкәләрендә эш белән тәэмин итәргә.

*З-2.0.0.2* Транспорт-коммуникация системасының сыйфат күрсәткечләрен күтәрергә. Транспорт-коммуникация системасы пассажирларның күчеп йөри алуын тәэмин итәргә тиеш: торак һәм эшлекле районнар эчендә – 30 минут эчендә; агломерацияләрнең үзәк эшлекле районнарында (үзәкләрендә) – 0,5 – 1 сәгать эчендә; агломерациянең үзәк эшлекле районнары (үзәкләре) арасында – 1,5 – 2 сәгать эчендә; күрше регионнарның агломерацияләре үзәкләре белән – 3 – 4 сәгать эчендә; транспортның төрле төрләрендә 1 Стратегиянең база (максатчан) сценарие буенча Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләре белән – 4 – 8 сәгать эчендә.

*З-2.0.0.3* Пространство белән идарә итүнең, перспектив мәгълүмат технологияләрен кулланып, яңа дәрәҗәсенә күчәргә. Идарә итүнең яңа системасында пространствоның барлык структур өлешләре һәм барлык мәнфәгатьле затлар күрсәтелергә, коллективка идарә итү алымнары кертелергә тиеш.

*З-2.0.0.4* Торак төзү күләмен арттырырга, гаиләләрне арзан торак белән тәэмин итәргә, яшәү өчен яраксыз булган торак фондын тотрыклы киметүне тәэмин итәргә, шәһәр мохитенең уңайлылыгын кардиналь арттырырга һәм уңайлы шәһәр мохитен булдыруда гражданнарның турыдан-туры катнашуы механизмнарын үстерергә.

**Базарлар**

<u>**СЦ-3**</u> **Татарстан Республикасының махсуслашу тармаклары регионара һәм глобаль базарларда конкурентлыкка сәләтле.**

**Ц-3.1** **Татарстан Республикасында глобаль конкурентлыкка сәләтле вертикаль үтеп кергән, нефть-газ химиясе кластеры һәм аңа бәйле булган, әмма чагыштырмача аерымланган, «Акыллы» материаллар» (яңа пластиклар һәм композитлар) һәм «Биосистемалар» инновацияле кластерлары нәтиҗәле эшли, алар өстәлгән бәянең зур өлешен бирәләр.**

**Ц-3.2** **Татарстан Республикасында энергетика кластеры һәм аңа бәйле булган «Тотрыклы энергетика» инновацияле кластеры актив эшли.**

**Ц-3.3** **Татарстан Республикасында өстәлгән бәянең зур өлешен бирә торган, вертикаль үтеп кергән «Автомобиль төзелеше»,**

«Авиатөзелеш», «Судно төзелеше» («Акыллы» машиналар» конвергент инновацияле кластерын төзеп) субкластерларыннан гыйбарәт глобаль конкурентлыкка сәләтле машина төзелеше кластеры нәтиҗәле эшләп килә. «Акыллы» җиһаз» инновацияле кластеры төзелде һәм нәтиҗәле эшли. Металлургиядә, җиңел, агач эшкәртү, мебель һәм композит сәнәгатендә кластерлы үсеш бара.

Ц-3.4 Татарстан Республикасында югары сыйфатлы продукция чыгаруга һәм өстәлгән бәя бирүгә юнәлтелгән, конкурентлыкка сәләтле вертикаль үтеп кергән агросәнәгать кластеры нәтиҗәле эшли. Аның кысаларында төп субкластерлар: ашлык, шикәр, май, яшелчә, бәрәңге, җиләк-җимеш, ит, сөт, аквакультура, шулай ук аерымланган «Экотуклану» инновацияле кластеры эшли.

Ц-3.5 Татарстан Республикасында глобаль конкурентлык сәләтле инфраструктура булдырылды. «Евразия хабы» транспорт-логистика кластеры, «Төзелеш кластеры» һәм «Төзелеш технологияләре һәм материаллары» кластеры нәтиҗәле эшли, торак-коммуналь хуҗалык һәм телекоммуникацияләр, шулай ук «Акыллы» инфраструктура» инновацияле кластеры үсә.

Ц-3.6 Татарстан Республикасында «Сәүдә һәм куллану сервислары» конкурентлыкка сәләтле кластеры нәтиҗәле эшли. Халыкның ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерү өчен глобаль конкурентлык базарын үстерү хисабына тотрыклы үсеш күзәтелә (максималь сыйфатлы товарның минималь бәясе, инфраструктурадан һәркем файдалана алу һәм уңайлылык, сервисның югары дәрәҗәдә булуы). Татарстан – «24/7» сәүдә һәм хезмәтләр күрсәтү территориясе, Евразия масштабындагы заманча коммерция үзәге. Сәүдә һәм куллану сервисларының классик төрләре үсә, юнәлеш заманча рәвешләргә таба борыла, шулай ук ерактан торып һәм электрон коммерция рәвешләре киң тарала.

Ц-3.7 Татарстан Республикасында түбәндәге конкурентлыкка сәләтле кластерлар эшли: «Финанс һәм һөнәри хезмәтләр күрсәтү», «Цивилизацияләрнең кушылуы» (мәдәният, туризм һәм рекреация), шулай ук «Акыллы» мәгълүмат технологияләре» инновацияле кластеры.

Ц-3.8 Татарстан Республикасында конкурентлыкка сәләтле түбәндәге социаль-инновацияле кластерлар эшли: «Фән һәм мәгариф» («Smart-мәгариф» инновацияле кластерын төзеп, 14 фәнни-белем бирү субкластерын берләштерә), «Сәламәтлек саклау» («Сәламәт яшәү рәвеше» инновацияле кластерын төзеп, өч территориаль субкластерны берләштерә).

Институтлар

<u>СЦ-4</u> Дәүләт, хосусый һәм дәүләти-хосусый институтларның тигез нисбәтле системасы конкурентлыкка сәләтле кластерларның, эшкуарлыкның (кече һәм урта бизнес) тотрыклы үсешен, эчке

**территориаль үсешне һәм тышкы кушылуны тәэмин итә.**

**Ц-4.1** **Татарстан Республикасында киләчәк белән идарә итүнең «эшли торган» системасы – Татарстан Республикасы үсешенә стратегик идарә итү системасы (ТР ССУР) – төзелгән һәм нәтиҗәле эшли, ул тотрыклы үсешкә, икътисадның һәм яшәеш сыйфатының конкурентлылык сәләтен арттыру өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән, даими эшләп килә торган проект мәйданчыклары һәм тышкы һәм эчке мохиткә диагностика ясый торган бер-берсенә ярашкан стратегик кораллар җыелмасын эшләүче, актуальләштерүче һәм контрольдә тотучы эшче төркемнәр кысаларында хакимиятнең, бизнесның һәм җәмгыятьнең үзара эшчәнлегенең сизгер механизмын кулланып, конкурентлык мохитендәге үзгәрешләргә оператив йогынты ясарга сәләтле системаны тәшкил итә.**

*З-4.1.0.1* Татарстан Республикасы үсешенең стратегик өстенлекләрен билгеләргә һәм мониторинг ясауны тәэмин итәргә.

*З-4.1.0.2* Проект мәйданчыклары кысаларында республика үсеше мәсьәләләрен хәл итүдә хакимиятнең, бизнесның һәм җәмгыятьнең катнашуын тәэмин итәргә.

*З-4.1.0.3* Кластер активациясен тәэмин итәргә.

*З-4.1.0.4* Эшчәнлеге стратегик программаларны һәм проектларны гамәлгә ашыруны күз алдында тотып оештырылган структуралар (институтлар һәм үсеш агентлыклары) төзеп, тармак һәм территорияне планлаштыру механизмнарының бер-берсенә ярашуын тәэмин итәргә.

*З-4.1.0.5* Үсешкә идарә итүгә дәүләти-хосусый партнерлык механизмнарын кертүне һәм дәүләт идарәсенә региональ бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыруны тәэмин итәргә.

*З-4.1.0.6* Стратегиягә мониторинг ясауны һәм актуальләштерелүен тәэмин итәргә.

**Ц-4.2** **Татарстан Республикасында заманча икътисадның һәм «акыллы» икътисадның конкурентлыкка сәләтле кластерлар портфеле булдырылды.**

Төп кластерлар түбәндәгеләр: нефть-газ химиясе һәм энергетика комплекслары кластерлары, машина төзелеше кластеры, «Фән һәм мәгариф» кластеры һәм 10 инновацияле кластер («Татарстанның технологик инициативасы» флагман проекты кысаларында), алар, Татарстан Республикасының уңышлы үсешенә һәм аның глобаль конкурентлыкка сәләтле булуына ирешүенә көчле йогынты ясаганга күрә, иң югары өстенлеккә ия.

Арадаш максатлар:

2016 ел – зоналар буенча кластерларны активлаштыру. **Татарстан Республикасында Кама кластеры актив үсә һәм өч икътисадый зона дәрәҗәсендә кластерга кагылышлы инициативаларны ачыклау һәм гамәлгә ашыру башкарыла. Югары потенциалга ия региональ кластерлар билгеләнде, алар регионара һәм/яисә глобаль дәрәҗәдә конкурентлыкка сәләтле була алалар.**

2017 – 2021 еллар – кластерлы система төзү. **Татарстан Республикасында**

**заманча икътисадның база кластерларын, шулай ук аларга бәйле рәвештә үзгәрешләрнең катализаторлары, ә киләчәктә – тулысынча үсеш лидерлары була алган «акыллы» икътисад инновацияле кластерларын булдыру гамәлгә ашырыла.**

| | |
|---|---|
| *З-4.2.0.1* | Кластерларны кадрлар ресурслары белән тәэмин итәргә (кластерларның лидерларын һәм төп белгечләрен эзләү, җәлеп итү, камилләштерү һәм җибәрмәү). |
| *З-4.2.0.2* | Инфраструктурага кагылышлы чикләүләрне бетерүне тәэмин итәргә; югары сыйфатлы инфраструктура һәм төп фондлар булдыруны стимуллаштырырга. |
| *З-4.2.0.3* | Клиентларны күз алдында тоткан конкурентлыкка сәләтле тармакларны һәм һәр кластерның нигезендә ятучы продуктларны ачыкларга һәм аларның үсешен тәэмин итәргә. |
| *З-4.2.0.4* | Кластерларның институтларга бүленеп үсүен стимуллаштырырга; административ каршылыкларның кимүен тәэмин итәргә; төп уенчыларны билгеләргә һәм кластерларны үстерү институтларын төзергә. |
| *З-4.2.0.5* | Инновацияләрдә лидерлыкны стимуллаштырырга. |
| *З-4.2.0.6* | Табигать ресурсларыннан нәтиҗәле һәм тотрыклы файдалануны тәэмин итәргә. |
| *З-4.2.0.7* | Кластерлар предприятиеләре өчен финанс ресурсларының һәркем файдалана алырлык булуын арттырырга, кластерларга ярдәм итүнең финанс механизмнарын камилләштерергә. |
| *З-4.2.0.8* | Кластерлар предприятиеләренең инновацияле продукциясенә ихтыяҗ булдыруны стимуллаштырырга. |
| **Ц-4.3** | **Татарстан – КУЭ өлеше югары булган бизнес алып бару өчен уңайлы регион.** |
| *З-4.3.0.1* | Татарстан Республикасында эшкуарлыкның кадрлар потенциалын үстерүне, эшкуарлык инициативасының үсешен һәм эшкуарларның кеше капиталында катнаша алуын киңәйтүне стимуллаштырырга. |
| *З-4.3.0.2* | Эшкуарлар (КУЭ субъектларын да кертеп) өчен инфраструктураның һәм фондларның сыйфатын һәм һәркайсының файдалана алырлык булуын тәэмин итәргә. |
| *З-4.3.0.3* | Эшкуарлык субъектларын бизнесның базардагы өлешен киңәйтүгә һәм нәтиҗәлелеген арттыруга стимуллаштырырга. |
| *З-4.3.0.4* | Административ каршылыкларны киметергә һәм бизнес алып бару өчен максималь уңай шартлар тудырырга; бизнеска һәм эшкуарлыкка ярдәм өлкәсендә хезмәттәшлекне һәм координацияне ныгытырга. |
| *З-4.3.0.5* | Инновацияләрнең бербөтен уңай экосистемасын төзергә, инновацияле эшкуарлыкның өлешен арттырырга. |
| *З-4.3.0.6* | Эшкуарларның (КУЭ субъектларын да кертеп) табигать ресурсларыннан тигез файдалана алуын тәэмин итәргә. |
| *З-4.3.0.7* | Финанс ресурсларыннан һәркем файдалана алуны арттырырга, эшкуарлыкка ярдәмнең финанс механизмнарын камилләштерергә; |

инвестиция-финанс өлкәсендә эшкуарлык үсешен стимуллаштырырга (КУЭ субъектларын да кертеп).

**Инновацияләр һәм мәгълүмат**

**СЦ-5** **Татарстан Республикасында инновацияләрнең тулы экосистемасы булдырылды, ул «акыллы» икътисад үсешендә, яңа материаллар, продуктлар һәм технологияләр булдыруда һәм коммерцияләштерүдә, республиканың глобаль конкурентлыкка сәләтле булуында Татарстан Республикасының лидер булуына мөмкинлекләр ача.**

**Ц-5.1** **Икътисадның һәм социаль өлкәнең инновациялек дәрәҗәсе югары.**

**Ц-5.2** **Технологияләр үсеше һәм алардан һәркем файдалана алу дәрәҗәсе югары.**

**Ц-5.3** **Мәгълүмат-коммуникация системасының сыйфаты югары.**

**Ц-5.4** **Реаль секторда һәм социаль өлкәдә цифрлы технологияләрне кертү.**

*З-5.0.0.1* Инновация системасы өчен кадрлар ресурсларын җәлеп итүне, әзерләүне, камилләштерүне һәм җибәрмәүне тәэмин итәргә.

*З-5.0.0.2* Инновация-инвестиция инфраструктурасын үстерүне тәэмин итәргә.

*З-5.0.0.3* Инновация экосистемасының ачыклыгы аша инновацияләргә ихтыяҗ булдыруны стимуллаштырырга.

*З-5.0.0.4* Рәсми һәм рәсми булмаган эчке институтларны үстерүне стимуллаштыру һәм Татарстан Республикасы Инновацион үсеш институтын төзү аша үз-үзен җайга сала торган һәм үзеннән-үзе үсә торган инновацияле системаны үстерергә.

*З-5.0.0.5* Инновацияләрне финанслау системасын стимуллаштырырга; венчурлы инвестицияләр базарын үстерергә.

*З-5.0.0.6* Икътисадый актив һәр гражданы цифрлы грамоталылыкка ия булган, ә дәүләт һәм бизнес югары цифрлы компетенцияләргә ия булган һәм аларны үз эшчәнлегендә системалы куллана торган Татарстан Республикасында цифрлы икътисадның үсүен тәэмин итәргә.

**Табигать ресурслары**

**СЦ-6** **Табигать ресурслары, тотрыклы үсеш принципларына нигезләнеп, нәтиҗәле файдаланыла.**

**Ц-6.1** **Табигать ресурсларыннан файдалануның югары нәтиҗәлелеге.**

**Ц-6.2** **Үсешнең югары тотрыклылыгы (киләчәк буыннарның объектив ихтыяҗларыннан чыгып, табигать ресурсларыннан тигез файдалану һәм, гомумән, табигатьне саклап калу).**

**Ц-6.3** **Җир ресурсларыннан файдалануның югары нәтиҗәлелеге.**

*З-6.0.0.1* Татарстан Республикасында табигать ресурсларыннан системалы һәм рациональ файдалануны тәэмин итәргә: булган табигать ресурслары җыелмасын ачыкларга һәм реестрны актуальләштерергә; предприятиеләрнең һәм проектларның ресурсларга ихтыяҗын билгеләргә; проектларны гамәлгә ашыру өчен кирәкле ресурсларның фаразлана торган балансын булдырырга; ресурс базасының рациональ

файдалануына квартал саен мониторинг ясарга.

*З-6.0.0.2* Тотрыклы үсеш системасын булдыруны һәм аның үсешен тәэмин итәргә.

*З-6.0.0.3* Әйләнә-тирә мохиткә экологик йөкләнешне киметүне тәэмин итәргә: табигать ресурслары белән эш итү өлкәсендә контроль системасын камилләштерергә; җитештерү технологияләренә экологик таләпләрне һәм аларны бозган өчен җаваплылыкны арттырырга; экологиягә караган проектларга дәүләт ярдәмен гамәлгә ашырырга.

*З-6.0.0.4* Җирләрдән файдалануның югары нәтиҗәлелеген тәэмин итәргә.

*З-6.0.0.5* Калдыклар белән эш итүнең комплекслы программасын эшләргә һәм аны гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә (калдыкларны максималь дәрәҗәдә җыюны һәм тулысынча эшкәртүне оештырырга).

*З-6.0.0.6* Зур сәнәгать үзәкләрендә атмосфера һавасының пычрану дәрәҗәсен киметүне тәэмин итәргә.

*З-6.0.0.7* Халык өчен, шул исәптән су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән заманча системалары белән җиһазландырылмаган торак пунктлар халкы өчен, эчә торган суның сыйфатын күтәрүне тәэмин итәргә.

*З-6.0.0.8* Идел елгасын саклап калуны һәм аның пычрануын булдырмауны һәм уникаль су объектларын саклап калуны тәэмин итәргә.

*З-6.0.0.9* Биологик төрлелекне саклап калуны һәм торгызуны тәэмин итәргә.

*З-6.0.0.10* Калдыклар белән эш итү системасын камилләштерүне һәм тупланган зыян объектларын бетерү тәэмин итәргә.

*З-6.0.0.11* Сәнәгать предприятиеләрен модернизацияләү өчен шартлар тудырырга һәм ресурс (шул исәптән энергетика да) һәм экологик нәтиҗәлелекнең югары күрсәткечләре белән аерылып торучы производство куәтләрен төзүне оештырырга.

**Финанс капиталы**

**СЦ-7** **Татарстан Республикасы дөньякүләм дәрәҗәдә инвестиция ягыннан кызыклы. Финанс системасы югары нәтиҗәле.**

**Ц-7.1** **Финанс ресурсларынннан һәркемнең файдалана алу дәрәҗәсенең югары булуы (инвестицияләр өчен аеруча кызыклы булу һәм инвестицияләр нәтиҗәлелеге).**

**Ц-7.2** **Финанс системасының югары нәтиҗәлелеге.**

*З-7.0.0.1* Финанс системасы өчен иң яхшы кадрларны җәлеп итүне тәэмин итәргә; бизнес вәкилләренең һәм халыкның финанс ягыннан грамоталылыгын арттырырга.

*З-7.0.0.2* Инвестиция инфраструктурасының һәм фондларның сыйфатын һәм алардан һәркемнең файдалана алуы дәрәҗәсен арттырырга.

*З-7.0.0.3* Инвестиция базарын үстерүне һәм инвестиция ресурсларының һәркем файдалана алырлык булуын арттыруны стимуллаштырырга.

*З-7.0.0.4* Дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарының инвестиция үсешенә сыйфатлы катнашуын тәэмин итәргә.

*З-7.0.0.5* Инновацияле алымнар һәм инвестицион үсеш коралларын куллануда алдынгылыкны тәэмин итәргә.

*З-7.0.0.6* Өстенлекле инвестиция проектларын гамәлгә ашыру кысаларында таби-

гать ресурсларыннан инвесторларның бертигез файдалана алуын тәэмин итәргә.

*3-7.0.0.7* Инвестиция системасының финанс механизмнарын камилләштерергә; өстенлекле инвестиция проектларын гамәлгә ашыра торган инвестиция процессында катнашучыларны стимуллаштыруны тәэмин итәргә; дәүләт ярдәме кораллары исемлеген киңәйтергә.»;

7) 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясенә 3 кушымтаның «Икътисад» юнәлеше буенча терминнар» бүлегендә:

түбәндәге эчтәлекле яңа утыз сигезенче – кырык икенче абзацлар өстәргә:

«Цифрлы грамоталылык – гражданнарның теоретик белемнәрне, шулай ук аларга җәмгыятьтә нәтиҗәлерәк һәм куркынычсызрак аралашу, икътисадый эшчәнлектә катнашу һәм шәхси тормышны оештыру өчен цифрлы инфраструктураны һәм цифрлы коралларны куллану мөмкинлеген бирә торган күнекмәләрне һәм үз-үзләрен тоту тәҗрибәсен үзләштерүе дәрәҗәсе.

Цифрлы инфраструктура – кулланучыларга – хуҗалык итүче субъектларга, гражданнарга һәм дәүләт институтларына цифрлы технологияләр базасында хезмәт күрсәтүләрне башкаруны тәэмин итә торган дәүләтнеке булган һәм дәүләтнеке булмаган техник системаларның (элемтә каналларының, программа комплексларының, мәгълүматларны эшкәртү үзәкләренең), алгоритмнарның, мәгълүматлар базаларының, стандартларның, беркетмәләрнең, техник регламентларның оешкан һәм идарә ителә торган бергәлеге.

Цифрлы икътисад – производствоның төп факторын цифрлы мәгълүмат тәшкил иткән хуҗалык эшчәнлеге, зур күләмле мәгълүматларны эшкәртү һәм аларга анализ ясаудан алынган нәтиҗәләрне файдалану, ул, хуҗалык итүнең традицион формалары белән чагыштырып караганда, производствоның, технологияләрнең, җиһазның төрле төрләренең, саклауның, сатуның, товарлар һәм хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүнең нәтиҗәлелеген шактый арттырырга мөмкинлек бирә.

Цифрлы кораллар – цифрлы икътисадка катнашучы төрле субъектлар арасында үзара хезмәттәшлек цифрлы рәвештә гамәлгә ашырыла торган технологик, норматив-хокукый һәм башка механизмнар.

Цифрлы компетенцияләр – бизнес-процессларның нәтиҗәлелеген һәм куркынычсызлыгын арттыру өчен цифрлы инфраструктурадан һәм цифрлы кораллардан файдалануның практик кулланыла торган күнекмәләре.»;

утыз сигезенче абзацны кырык өченче абзац дип санарга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 05 апрель
№ 31-ТРЗ